**Альфия Ситдикова**
**Вера Хамидуллина**

# ДВА РОДНИКА РОДНОЙ ЗЕМЛИ

# ТУГАН ЯКНЫҢ ИКЕ ЧИШМӘСЕ

Стихи и поэмы

Казань
Татарское книжное издательство
2007
УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
С48

**Ситдикова А.М.**

Два родника родной земли / Туган якның ике чишмәсе: стихи, поэмы / Ситдикова А.М., Хамидуллина В.П. – Казань: Татар. кн. изд.-во, 2007. – 207 с. – 1000 экз. – ISBN 978-5-298-01605-6

В книгу вошли стихи и переводы двух поэтесс, живущих в городе Набережные Челны. В их стихах извечные житейские темы звучат одинаково гармонично и с большим чувством.

ISBN 978-5-298-01605-6
© Татарское книжное издательство, 2007
© Ситдикова А.М., Хамидуллина В.П., 2007

## ОТ АВТОРОВ

Во все века наука, искусство и литература нуждались в поддержке. Покровителями муз являлись царские особы от Екатерины до Николая Романова, представители купечества и дворянства, промышленники. Это и братья П.М. и С.М.Третьяковы, и С.Т.Морозов, и С.И.Мамонтов. В Татарстане всем известны фамилии таких меценатов, как Рамиевы, Акчурины, Стахеевы.

И вот сейчас эти традиции возрождаются. Возрождаются не по приказу, а по зову сердца, из любви к прекрасному, из чувства патриотизма и веры.

2007 год объявлен в России Годом русского языка и литературы, в Татарстане этот год — Год благотворительности.

Тем ответственнее для нас, авторов этой книги, что нас поддержали и поверили в то, что «Два родника родной земли» действительно та книга, которая сблизит две великие культуры — татарскую и русскую, позволит читателям познакомиться с оригинальными текстами и их переводами и, что наверное не менее важно, проведет по самым сокровенным тропинкам чувств двух поэтесс-современниц, пишущих на русском и татарском языках.

Рукопись книги обсуждалась в Союзе писателей Татарстана. Большую помощь оказали **Лилия Газизова** — руководитель отдела русской литературы и переводов и **Сергей Малышев** — редактор журнала «Идель», поэт-переводчик, руководитель секции переводов при Союзе писателей.

**Николаю Алешкову** и **Галимьяну Гильманову**, уважаемым, известным деятелям татарской и русской литературы в нашей республике, отдельная сердечная благодарность за тонкие поэтические предисловия к этому сборнику.

Но, дорогие друзья, читатели, «Два родника родной земли» не сумели бы пробиться на свет без финансовой поддержки со стороны не только наших друзей-предпринимателей, но и руководителей крупных организаций Республики Татарстан.

Прежде всего **Фардиева Ильшата Шаеховича —** генерального директора ОАО «Татэнерго»;

**Зайнутдинова Альхата Фатиховича —** генерального директора ЗАО «КамАЗжилбыт»;

**Штейнберга Леонида Даниловича —** председателя совета национальных общин г. Набережные Челны, генерального директора ООО «Кама-Тракс»;

**Хисамова Флюса Фаниловича** — директора ООО ТПК «Курзан-Медиа» и просто нашего доброго, верного друга;

**Хамидуллина Рафаиля Ризвановича** — руководителя ООО «Резван».

Примите от нас низкий поклон и слова искренней благодарности!

## АВТОРЛАРДАН

Фән, сәнгать һәм әдәбият һәр гасырда да ярдәмгә мохтаҗ булган. Илһамчыларның яклаучылары булып патшабикә Екатеринадан алып Николай Романов, купец һәм дворяннар, җитештерүчеләр торганнар. Болар — бертуган П.М. һәм С.М.Третьяковлар, С.Т.Морозов һәм С.И.Мамонтов, ә Татарстанда Рәмиев, Акчурин, Стахеев кебек меценатларның исемнәре билгеле.

Һәм менә хәзер шушы традицияләр яңара. Кемнеңдер боерыгы буенча түгел, ә йөрәк кушуы, гүзәллеккә мәхәббәт, патриотик хисләр һәм ышаныч нәтиҗәсендә.

2007 ел Россиядә — Рус теле һәм әдәбияты, ә Татарстанда Хәйрия елы дип игълан ителде.

«Туган якның ике чишмәсе» татар һәм рус халыклары мәдәниятен бер-берсенә якынайтучы, укучыларны текстның оригиналы һәм аларның тәрҗемәләре белән таныштырырга мөмкинлек бирүче, ә иң мөһиме — хәзерге заманда ике телдә язучы ике шагыйрәнең иң серле һәм эчкерсез хисләре сукмагында очраштыручы китап икәнлегенә ышанып, ярдәм итүләре безгә — әлеге басма авторларына зур җаваплылык өсти.

Китапның кульязмасы Татарстан Язучылар берлегендә дә хуплау тапты. Рус әдәбияты һәм тәрҗемә бүлеге җитәкчесе **Лилия Газизова** һәм «Идел» журналы редакторы, шагыйрь-тәрҗемәче, Язучылар берлеге каршындагы тәрҗемә бүлеге җитәкчесе

**Сергей Малышев** безгә зур ярдәм күрсәттеләр.

Республикабызның танылган татар һәм рус әдәбияты эшлеклеләре **Галимҗан Гыйльманов** һәм **Николай Алешковларга** җыентыкка нечкә шигъри тел белән сүз башы язганнары өчен без бик рәхмәтле.

Татарстан Республикасының эре оешма җитәкчеләре, эшмәкәр дусларыбыз ярдәм итмәсә, «Туган якның ике чишмәсе» укучы дусларыбызга барып ирешмәс иде.

Барыннан да элек «Татэнерго» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Илшат Шәех улы Фәрдиевкә**, «КамАЗжилбыт» ябык акционерлык җәмгыяте җитәкчесе **Әлхәт Фатыйх улы Зәйнетдиновка**, Яр Чаллы шәһәренең милли общиналар советы рәисе, «Кама-Тракс» җаваплылыгы чикләнгән оешманың генераль директоры **Штейнберг Леонид Даниловичка**, «ТПК Курзан-Медиа» җаваплылыгы чикләнгән оешма директоры **Флүс Фәнил улы Хисамовка**, эшмәкәр, «Резван» җаваплылыгы чикләнгән оешма җитәкчесе **Рафаил Ризван улы Хәмидуллинга** чиксез рәхмәтләребезне белдерәбез.

## Два родника родной земли

Два родника моей родной земли,
Два древних языка — татарский, русский
Венок над головой моей сплели
Из добрых слов, простых и безыскусных.

Я жажду утолю одним из них,
Журчаньем налюбуюсь я другого...
На них я говорю, слагаю стих,
В них нахожу я точность рифм и слова.

Им Мать-Земля все силы отдала.
В них мир и дружба льются сквозь столетья.
Народа золотая голова
Их сохранила в бурях лихолетья.

Вот где народной мудрости исток!
Они питают корни двух деревьев,
Чтоб не засох побег, листок, цветок
Двух мировых культур, как мир наш древних.

Не дай иссякнуть, Бог мой и Аллах!
Тем силам, что хранятся в родниках.

*Вера Хамидуллина*

## Туган якның ике чишмәсе

Туган якның ике чишмәсе без.
Борынгы тел: татар һәм рус теле.
Кабатланмас гади сүзләр белән
Баш очына такыя-мәрҗән тезде.

Бер чишмәдә сусавымны басам,
Икенчесен тыңлап ләззәтләнәм.
Шул тел белән сөйлим әйтер сүзем,
Рифмаларга салып энҗе тезәм.

Җир-Анадан яшәү көче алган
Ул чишмәләр ага гасыр иңләп.
Һәрбер чорның моңы сеңгән сутын
Халык хәтере белән була тиңләп.

Ул чишмәләр халык акылы белән
Сугарадыр ике агач тамырын.
Яшь үсенте кебек тармакланыр
Ике бөек милләт тагын-тагын.

Аллаһым! — Бог! Берүк киметмә син,
Чишмәләрдә булган яшәү көчен!

*Әлфия Ситдыйкова тәрҗемәсе*

## Где живет счастье

Со страниц этой книги две женщины, две поэтессы проникновенно говорят нам о том, что счастье живёт в душе. И не надо спрашивать, из чего складывается женское счастье. Конечно, из любви. Но легко ли душа обретает любовь?

«Я пришла к тебе, прошагала века,
Я заблудилась в тебе…» —

говорит Лейла Меджнуну.

«В глаза твои взглянув, я забредаю
В глубь моря…» —

продолжает она. Какой же должна быть жажда любви, чтобы прошагать века? И оцените смелость женского сердца, его способность к самопожертвованию, ведь забрести в любовь, как в глубь моря, рискованно, ибо на море случаются девятибалльные штормы.

Но все страдания и муки искупляются божественным светом взаимности, и тогда возникают признания, от которых суровому мужскому началу не устоять:

Ты — мой светлый сегодняшний день,
Мое прошлое и грядущее…

Твой взгляд — душа, как факел, возгорит,
И в сердце вспыхнет отсыревший порох…

Ох уж эти обворожительные восточные мотивы! Хочется читать не останавливаясь, хочется слушать и слушать признания из желанных уст — порох-то ведь и в тебе не отсырел, добытчик, защитник, муж и отец! Ответь огнём на огонь, видя:

А по плечам тихо платье стекает,
Освобождая прекрасное тело!..

Обо всем этом рассказывает своим читателям Альфия Ситдикова. Не менее страстно и взволнованно вторит ей Вера Хамидуллина. Она прослеживает женскую судьбу с момента рождения. Детство — это «край, где счастье безмятежно». Но в безмятежность и природа, и Творец вносят томление духа, ноту тревоги и смутного ожидания, постепенно подготавливая девочку к подвигу слияния с мужским началом, к подвигу материнства, к пониманию того, что «любовь — красивая мелодия!». Но не только это. К сожалению, и юная принцесса рано или поздно, но неизбежно переступит тот порог, за которым

Осень раздевается красиво,
Сбрасывая золотой наряд!
Почему ж убого и тоскливо
Рощи обнажённые стоят?

Быть готовой к этому — подвиг не меньший.

Любовь иногда покидает свое жилище, и это — трагедия:

Где-то там далеко-далеко,
Где-то там за дождями, снегами
Было сердцу тепло и легко,
Мы любви нашей песни слагали.
Но ушла в никуда чистота.
В закоулках ушедшего лета
Заблудилась любовь… А душа,
Словно нищий, в лохмотья одета.

Но как катарсис, как очищение, есть и преодоление трагедии. И женщина, красивая, всё познавшая, уверенно завершает исповедь:

Я судьбу благодарю.
Не ругаю, не корю.
У других бывает хуже.
Что, неправду говорю?..

Я друзей домой впущу,
Хлебом-солью угощу,
И, как нитку сквозь иголку,
Все печали протащу.

Будет светлой жизнь моя,
Как в ажуре кисея,
Дом мой будет полной чашей.
Будем вместе: ты и я…

И несколько слов в заключение.

Анна Ахматова когда-то воскликнула: «Я научила женщин говорить, но, Боже, как их замолчать заставить!» Конечно, в этих строках — добрая, лукавая ирония. Дескать, ничто не заставит! И — слава Богу! В женской поэзии есть особая мудрость — мудрость примирения двух основополагающих начал. Женская поэзия — это тот белый платок, которым жена или мать останавливают распрю, междоусобицу. Замечательно, что в нашем конкретном случае это понимают не только Вера Хамидуллина и Альфия Ситдикова, которых озарила прекрасная идея перевести стихи друг друга, но и издатели, выпустившие их замечательную книгу на двух государственных языках Республики Татарстан. Бик зур рахмат!

*Николай Алешков,*
*поэт, лауреат республиканской*
*литературной премии*
*им. Г.Р.Державина*

## Иҗатында язмыш бар

Миңа үз гомеремдә бик күп шагыйрьләрнең олы әдәбият мәйданына чыккан мизгелләрен күрергә туры килде. Әмма араларында: «Мин бәхетне эчәм бүген Кушып кыргый балга», — дип, кайнап торган тормыш, дөресрәге, язмыш эченнән калыккан каләм ияләре сирәк булгандыр. Әлфия Ситдыйкова — әнә шундый шагыйрьләрдән. Аның өчен иҗат язмыш кебек, мәхәббәт кебек — бер ачы да бер татлы:

Учымда төн. Ак кәгазьгә
Тама илһам тамчысы.
Бөтен җанны айкап ала
И бу илһам ачысы!

Билгеле инде: шагыйрь каяндыр көч алып яшәргә тиеш. Аның бу көч-егәрлекне бирердәй табигый һәм рухи чыганаклары булырга тиеш. Әлфия Ситдыйкова өчен ТУГАН ЯК — шундый чыганакларның берсе:

Әрем исе, татлы сагыш булып,
Күңелемә кереп урын ала.
Бертуктамый бәллүр бишегеңдә
Тирбәләм мин — һаман сабый бала.

Туган җир — шагыйрә өчен матур сүз яки хатирә генә түгел. Аның өчен туган җир — сихри көч тә: «Һавадагы сөт исеннән Күк исереп йолдыз ата», кендек әбиләрнең изге догасы да, аналарның таң җиледәй йомшак кулы да, кояш яктысын капларга тырышкан «кара хәбәр» дә, «күңел түреннән шытып чыгып, хәтер каберенә тамган гөлләр» дә, «йөрәк тулы зәңгәр моңнар» да, «канатларын кагып, мәңгелеккә таулар ягына очып киткән бөркет»тә, су баса дип күчерелгән күрше авыл шәүләсе дә...

Яшәү өчен, димәк, иҗат өчен дә, иң күп көчне шагыйрь СӨЮ-МӘХӘББӘТтән ала. Шулкадәрле үк аңа бирә дә. Дөресен генә әйткәндә, аның бөтен яшәеше — мәхәббәттән, иҗаты сөюдән тора. Ул мәхәббәттә яшәми дә кебек, ул анда яна, дөрли... Аның бу халәтендә мәхәббәт белән иҗат, кавышу белән аерылышу, бәхет белән сагыш бергә яши:

Тезелде сүзләр кәгазьгә,
Киткәндә синең яннан.
Үзем китеп барсам да бит,
Җан белән синдә калам!..

Әлфия-шагыйрәнең сөюе чын шагыйрьләрчә. Ул язмыш ихтыярына буйсынып яшәүче, бары тик яздан, наздан гына торган җан түгел. Аның тынгысызлыгына һәм дуамал дәртенә бер генә сөю дә аз, ләкин ул һәр сөю саен сафлана, яктыра гына бара. Шуңа күрәдерме, аның гыйшкы бүтән беркемнекенә дә охшамаган:

Кыргый идем, тансык идем,
Көткәнеңне белдем.
Үз-үземнән оялсам да,
Бүген сиңа килдем.

Шагыйрәнең яшәеше, иҗаты өчен тагын бер чыганак — тирә-яктагы кешеләр. Ул кешеләр тудырган дөнья. Бу дөньяда шатлык та, сагыш та гаять күп, өмет белән өметсезлек тә җитәрлек... Боларның барысы да бер сүз белән МОҢ дип атала:

Кем ярасын кем дәвалар,
Җанга тоташ моң тулгач?
Җиргә килгән һәрбер кеше
Ул — яралы сандугач...

Шагыйрә яши, иҗат итә. Ул шулай язмыш тудыра. Бу язмыш юлы көзгә якынлашып килсә дә, ул яшьлек дәртен, хыял-омтылышларын саклап кала белә. Бу яклап Әлфия Ситдыйкованың шагыйрәлеге тагын бер мәртәбә сынала кебек:

Гомер үткән, көзгә кереп барам,
Чык тамчысы минем күзләрдә.
Бала чакның якты ал кояшы,
Төсле күбәләкле ямьле җәе
Озата бара алтын көзләргә...

Әйе, чын шагыйрьлекне сынап карауның бер генә юлы мәгълүм: бу каләм иясенең әсәрләрендә тормыш гаме, яшәү мәгънәсе бармы? Һич икеләнмичә әйтергә мөмкин: Әлфия Ситдыйкованың шигырьләрендә чын мәгънәсендә гомер һәм язмыш кичерәсең, яшисең. Чөнки тоясың: гүя аларда кешелекнең бөтен борчу-гаме, хыял-омтылышлары, иң мөһиме, олы мәхәббәте тупланган.

Әлбәттә инде, камиллекнең чиге юк. Шигъри осталыкка, образлылыкка, поэтик тоемчанлыкка өйрәнәсе дә өйрәнәсе әле. Камиллеккә омтылу да чын шагыйрьләр халәте. Әлфия Ситдыйкова иҗатында бу үсеш күзгә күренеп тора: шигырьдән шигырьгә, фикердән фикергә, хистән хискә ул өлгерә бара. Үсә, камилләшә, әмма беренче шигырьләреннән үк тапкан төп хисне — шигърияттне шигърият иткән тойгыны югалтмый, аның бер тамчысын да түкми-чәчми саклап кала белә:

Инәдән җеп үткәргәндәй,
Сагышларда җанны сыныйм!

Әйдәгез, тормышка, яшәешкә үтә дә сизгер шагыйрә иҗатына ак юл, якты сагыш телик! Калганы — язмыш мәсьәләсе...

*Галимҗан Гыйльманов,*
*язучы, Татарстанның атказанган*
*сәнгать эшлеклесе*

Поэзия Альфии Ситдиковой
*в переводе Веры Хамидуллиной*

**Бер җылы сүз**
**Одно теплое слово**

*** * ***

Учымда төн. Ак кәгазьгә
Тама илһам тамчысы.
Бөтен җанны айкап ала
И бу иҗат ачысы.

Бар төнемне, кулдан килсә,
Салыр идем шигырьгә.
Илһам уты янып бетеп
Әйләнгәнче күмергә.

*** * ***

Качаю ночь в руках... На белый лист
За каплей капля льется вдохновенье.
Переворот в сознании, каприз...
Нет — муки творчества, души горенье.

Все ночи, если б только я смогла,
Зарифмовала б в трепетные строчки.
Пусть чувства, свечкой выгорев дотла,
Расставят на листе нагаром точки.

## Җиде төн

*(Гарәп мотивлары)*

**Беренче төн**

Әй, беренче кабат күрү
Синең сихерле дөньяң.
Син — бер Мәҗнүн, җырчы Гашыйк,
Ә мин бит Ләйләң булам.

Гасыр кичеп килдем сиңа,
Адаштым сиңа кереп.
Яшим бүген бу дөньяда
Бәхетнең тәмен белеп.

**Икенче төн**

Тезелде сүзләр кәгазьгә,
Киткәндә синең яннан.
Үзем китеп барсам да бит,
Җан белән синдә калам.

Кем синең серне ачалган?
...Мин тетрәп китеп барам.
Синең җылы карашыңнан
Төзәлә йөрәк ярам.

Кем син? Беренче Гашыйкмы,
Яңа шагыйрем мәллә?!
Җан күзеңә бактым шашып,

Хушлашып киткән мәлдә.

**Өченче төн**

Мин бүтән... дип дәшәсең син,
Янып, яндырып сөям...
Күрәсеңме, бүген мин дә
Син яккан утта көям.

Сөю китердең син миңа,
Талантың көчле, көчле.
Сөя, сөйдерә белгәнгә
Дөньялык куя бишле.

Син бердәнбер Шагыйрь җирдә
Мәҗнүн бүләген алган.
Йөрәкне түгел, җаннарны
Сөю утына салган.

Шагыйрьне ярат, дисең син,
Талантым өчен ярат...
Сиңа китерде җәйләрдә
Шигырьләр тулы кораб.

**Дүртенче төн**

Мин Ләйләме? Белмим кем мин.
Тик дөрләп яна беләм.
Синең күзләр аша карап
Тирән диңгезгә керәм.

Бер түгел бу, ике йөрәк
Кушылып бергә яна.
Сиңа бу җыр. Яраттырдың,
Инде онытып кара.

**Бишенче төн**

Очрашу вәгъдә ит миңа...
Яндырды карашларың.
Ак, якты төннәрдә эзлим
Мин Сөю тарафларын.

Арабызда ничәнче төн...
Гүя, бер гасыр ара.
Сиңа килгәнчегә кадәр
Йөрәктә күпме яра.

Вәгъдә бирдем, киләм, дидем.
Каршы ал, сөйгән ярым!
Сиңа оча Сөю кошым
Кагып пар канатларын.

**Алтынчы төн**

Сүзләрем яңа түгелдер,
Яңартып әйтәм сиңа.
Мәхәббәт өчен үлемне
Җиңгән кыз сөйли, тыңла.

Мәҗнүнен күреп, Ләйләдәй
Ул гашыйк сиңа, гашыйк.
Гомерләр чикләп бирелгән,
Яратып калчы, ашык!

Үлем теләвем түгел бу,
Яшәргә телим сөеп.
Мәңге яшәүнең серен һәм
Сөюнең тәмен белеп.

### Җиденче төн

Җиде диңгез артларына
Мин эзләп килдем сине.
Кавыштырды икебезне
Айның җиденче төне.

Сиңа китергән юлымда
Җитмеш җәһәннәм кичеп,
Килдем китәр өчен җирдән
Сөю шәрабын эчеп.

Гасыр кичеп килдем сиңа,
Пешеп, көеп, туңып та.
Яндыр әйдә сихерчедәй,
Яндыр син мине утта.

## Семь ночей

*(Арабские мотивы)*

### Первая ночь

Эй, что с твоим миром эоловых струн,
Встреча моя первая?
Ты ведь влюбленный певец Меджнун?
Твоя Лейла я!

Я пришла к тебе, прошагала века
И заблудилась в тебе.
Живу, твой мир пригубив слегка,
Кубок счастья сжимая в руке.

### Вторая ночь

На лист бумаги капали слова,
Когда я уходила от тебя.
Я уходила, а душа моя
С тобой осталась, лишь тебя любя.

Смогу ли эту тайну приоткрыть?
... Я ухожу, я так возбуждена.
От ласкового слова твоего
Исчезнет ран душевных глубина.

Кто ты, возлюбленный моей мечты
Или даривший песни мне поэт?
В глаза твоей души в прощальный миг
Смотрела и искала в них ответ.

**Третья ночь**

«Другим становлюсь,— шепчешь мне ты,—
Воспламеняюсь, нежно люблю»...
Видишь, я тоже в огне мечты
Страстной, зажжённой тобой, горю.

Ты подарил мне любовь свою.
Ярким талантом играл, блистал!
Этой любви, что сейчас я пью,
Весь мир в восторге рукоплескал.

Ты мой главный поэт на земле.
Ты Меджнун, достойный подарка.
Сердце, душу отдам тебе,
На костер любви взойду жаркий.

Говоришь: «Полюби поэта
За талант, что бьётся, как волны!»
В мою гавань привел ты летом
Свой корабль рифмами полный.

**Четвертая ночь**

Я Лейла ли? Возможно, я не знаю.
Но знаю, как неистова любовь.
В глаза твои взглянув, я забредаю
В глубь моря, уходя от берегов.

Из двух сердец сложу одно большое.
Они луною полной возгорят.
Я песню подарю тебе прибоем.
Ты полюбил, и нет пути назад.

**Пятая ночь**

Мне свидание, милая, обещай, —
Взгляд твой страстный сжигает меня.
Я пытаюсь найти в туманных ночах
Островок любви обитания.

Между нами скопление стольких ночей,
Год за годом, из века в век.
Столько ран накопилось в душе моей, —
Сколь в пути проставлено вех.

Я дала обещанье к тебе прийти.
Ты, возлюбленный, только жди.
И на белых крыльях к тебе летит
Птица нежной моей любви.

**Шестая ночь**

Я новых слов тебе не говорю.
Я ими песню новую пою.
Послушай! Как любовь дарит свою,
Стоящая у жизни на краю.

Как Лейла, что Меджнуна увидав,
Я полюбила твой веселый нрав.
Поторопись любить, любовь познав.

Жизнь быстротечна наяву и в снах.

Я не стремлюсь во мрак небытия,
Хочу лишь жить, жить, пламенно любя.
Разгадку вечной жизни для себя
Найду, вкусив любовь, вкусив тебя.

**Седьмая ночь**

Из-за семи морей я шла,
Тебя искала и нашла.
И вместе нас соединяет
Тень месяца и ночь седьмая.

Мой путь был соткан из преград.
Раз семьдесят входила в ад,
Чтоб рай земной познать смогла я,
Любовь хмельную выпивая.

Я шла, переходя свой век.
В нем было жарко, падал снег.
Что ж, разжигай огонь любовный,
Сжигай меня, колдун мой добрый.

*** * ***

Хистән исердем, дисең син,
Мин дә айнымыйм һаман.
Егылам да, торып, күктән
Үрелеп йолдыз алам.

*** * ***

Иңнәреңә баскан Сөю йөген
Бүлешергә килдем.
Күзләреңдә йолдыз төсле янган
Шигырь утын күрдем.

Укыдың син, күзгә туры карап,
Язган шигыреңне.
Шундый таныш булган Сөю җырын
Язган Шагыйрь синме?!

Җан түренә керде һәрбер сүзең,
Юанмадым ләкин.
«Син янасың, су биримме?» — дигән
Кыз шул бүген ятим.

Син башкага атап шигыреңне
Укыганны белгән.
Ә шулай да тере суы тотып
Ул яныңа килгән.

*** * ***

Ты говоришь, что пьян от чувств, —
Я до сих пор хожу хмельная.
Я падаю, встаю, взмываю,
С небес срезаю звездный куст.

* * *

Я пришла разделить с тобой ношу любви,
Что лежит на твоих плечах.
Я увидела пламенных звезд кульбит
И мерцанье свечи в очах.

Ты читал, обращаясь к глазам моим,
Стих, что выпестовал и сплел.
Он до боли знаком. Это Песня Любви.
Где, поэт, слова к ней нашел?

Смысл их в душу мою влетал, витал,
Но в унынье душа пришла.
Я, несчастная девушка — сирота,
Чем твой пыл остудить не нашла.

Было видно душе, ты стихи сложил
И читал их когда-то другой.
Но неважно это, и вот, держи:
Это кубок с живой водой.

* * *

«Кайт кире!» — дип дәшәсең син һаман,
Кире кайтмый язлар.
Син үкенмә, гасыр озын әле,
Алда тагын яз бар.

«Әйтми киттең соңгы сүзең!» — диеп
Дәшмә үткәннәргә.
Кире кайтмый кайчак, «кабат кайтам!» — диеп
Киткәннәр дә.

* * *

Яратмавың белән яраттырдың...
Хатлар язган идең.
Моңы тынмый чыңлый әле һаман
Яңгыраган көйнең.

Тиле дия күрмә йөрәгеңне,
Анда ялкын, наз бар.
Кемдер китә җирдән назны белми,
Йөрәгендә гел кар.

Ерактагы йолдыз якын була,
Яшә шуны тоеп.
Яратмаган булып кылансам да,
Яшим Гашыйк булып.

* * *

«Вернись обратно», — ты зовешь меня,
Но не вернуть ушедшую весну.
Не зарекайся веснам изменять, —
Век длинный поднесет их не одну.

«До встречи!» — прошлому не говори.
Ведь сколько по земле я ни кружусь,
Назад не приведут меня пути,

Хоть обещанье дал: «Я вновь вернусь!»

* * *

«Я не могу назвать тебя любовью...» —
Летит мне весточка.
И до сих пор она звучит мне болью
В мелодии смычка.

Зачем твердить, что это сердца глупость —
Вихрь ласки трепетной.
Страшней нести и холодность и сухость
Без ласки в мир иной.

Далекая звезда мечтает втайне
Быть с неба сорванной.
Я притворяюсь безразличной. Дай мне
Жить лишь одним тобой.

* * *

Кирәк түгел гамәл юмарт булу
Чамасыннан артык.
Күзне түгел, йөрәгеңне хәтта
Ятлар алыр тартып.

Бар да калыр. Өзелеп сөйгән ярың
Ятлар кочагында.
Сала җанны булу артык юмарт
Тәмуг учагына.

* * *

Как неуместно в чувствах щедрой быть:
Проявите беспечность —
И кто-то сердце милое, глаза
Вмиг выкрадет навечно.

Увидят, подберут, — и сладкий ваш
Уже в чужих объятьях.
Вот так в порыве щедрости в костер
С души сорвете платье.

## Назга сусау

Җаным кипшеп яргаланып бетте.
Мин сусадым җылы назларга.
Мөмкин булса, тагын бер мәртәбә
Кайтыр идем якты язларга.

Күзләрдә дә язлар килә, диләр...
Сөю канатына ияреп.
Сагышлардан җанны чистартам мин,
Кырга чыгып, җилдә җилгәреп.

Яргаланып беткән җаным беркөн
Әй кинәнер сөю сутына.
Өмет белән канатларны җилпеп

Керәм кайнар учак утына.

Чиксезлеккә кадәр озатырмы
Шушы сусау минем җанымны?!
Кайда соң син, кайтаручым миңа
Сөю тулы якты язымны?!

Йөрисеңме син дә назга сусап,
Нишләтергә белми җаныңны?
Кайчан явар күптән тансыклаган
Мәхәббәтнең назлы яңгыры?!

Гасыр чиген ялгыз атлап кердем,
Урау булды килер юлларым.
Чигәмә бәс сипкән сине эзләп,
Сине көткән назсыз елларым.

## Жажда ласки

Душа растрескалась, засохла
От жажды ласки, от желанья.
Еще вернуть она хотела
Былой весны очарованье.

Но чувствую, весна вернется
Теплом и светом в «бабье лето»...
Я сердце пронесу над полем,
Очищу от тоски под ветром.

И в трещины души однажды
Вольется сок любви нектаром.
И я под крыльями надежды
Вверх взмою пламенным пожаром.

Возможно, что направит в вечность
Мое сердечко жажда ласки?
Так где же тот, кто мне подарит
Весну любви, наполнит сказкой?

Где бродишь ты, томясь от жажды,
Припасть душой куда не зная?
Когда же хлынет дождь желанья
Нас лаской светлой освежая?!

Из века в век, через пороги
Иду запутанной дорогой.
Виски мне иней укрывает,
Живу без ласки недотрогой.

Кара бөдрә чәчләреңне синең
Еллар тарап җилдә тузгыткан.
Син иртәрәк, ә мин соңлап үткән
Гасыр чиге сызган сызыктан.

Ә шулай да очраштырды язмыш
Сусап арган ялгыз җаннарны
Төреп нурга, салкын кышны ярып,
Сөю алып килгән язларны.

Мин сыендым синең куеныңа,
Эреп агыйм диеп назыңнан.
Ике гасыр кичеп очраштык без,
Без гасырның кайсы языннан?!

Сирәкләнгән чәчләреңнән сыйпыйм,
Уйныйм назлап язгы җил сыман.
Бу назларга ике гасыр язы,
Ике гасыр җәе, көз сыйган.

Кышларның да ак карлары күчкән
Безнең белән шушы язларга.
Бирешмәбез килгән картлыкка да,
Җан җылытыр җылы наз барда.

Без бит ике гасыр кичкән җаннар,
Безнең гомер түгел бер генә.
Мин дә гасыр туфрагында шытып
Чәчәк аткан нәфис гөл генә.

Гөл бәйләме тоткан кулларыңа
Салдым бүген җырлы язмышны.
Белмим, сиңа мин бер сагыш микән,
Гасыр биргән яңа табышмы?!

И черный волос твой кудрявый
Года запутали под ветром.
Чуть раньше ты, а я чуть позже
Пришли на встречу с новым веком.

Нас подвела судьба друг к другу,
Соединила наши души,
Лёд растопив на сердце светом,
Чтоб мы весну могли послушать.

И я, прильнув к твоим объятьям,
От ласк растаяла мгновенно.
Где наша встреча происходит:
В какой весне и измеренье?!

Касаюсь прядей поредевших —
Порывы чувств теперь степенней.
Нас двух веков земная ласка
Укрыла под своею сенью.

И пусть зима метёт снегами,
Весне не уступая кресло,
Мы в душу старость не впускаем, –
Лишь ласка в ней имеет место.

Мы пережили век ушедший,
И жизнь имеет продолженье.
Я сбросила наряд осенний
И начала свое цветенье.

Букет тебе вложила в руки
И душу в щебетанье птичьем.
Кто для тебя я: так — случайность,
Или находка в жизни личной?!

Җавап көтә сусаган гөл синнән,
Бер тамчы су көтә иреннәр.

Күрәсеңме, безгә елмаялар
Чәчәк аткан ап-ак сиреньнәр.

Язгы нурлар назлаганга алар
Ачып куйган чәчәк таҗларын.
Нурлар булып җанны яктыртсыннар
Синең ихлас, җылы назларың.

Минем җаным назга сусап кипкән,
Мин тилмердем яңгыр көтеп, наз.
Сиңа килдем сөюемнән шашып,
Гомер дәфтәремә шигырь яз!

Илһам кошың канатларын җәеп
Бер сыйпасын ике иңемнән.
Бәлки, мин дә җырчы кош булырмын,
Йогып калган шигырь җиленнән.

Бәлки, мин дә Наз җырчысы булып
Кунармын да күңел талыңа,
Җыр сузармын Гашыйклыгың мактап
Гомернең бер якты таңында.

Илһам кошың канатларын кага,
Җыеп алам каурый мамыгын.
Җырга кушам Назлар бүләк иткән,
Сөю биргән җиһан аклыгын.

Ответа ждет цветок засохший.
Ждут мои губы каплю влаги.
Сирень нам улыбнулась в окна,
Добавила своей отваги.

Ее бутоны в ласке света
Открыли лепестки соцветий.
Пусть душу мне омоет солнце
И твоя нежность жаром летним.

Душа растрескалась, засохла
От жажды ласки. Как от ливня,
Я от любви теряю разум –
Журчит твой стих в тетради жизни.

И будто птица вдохновенья,
Взмахнув крылом, ласкает плечи.
Стихи, как дуновенье ветра
У певчей птички душу лечат.

Я стану певчей птицей ласки,
Чтоб петь под ивой гимн хвалебный.
Я воспою твою влюбленность
Зарею утренней приветной.

Мне птица вдохновенья с крыльев
Роняет пух и строчки сказки.
Из них тебе слагаю песни, —
Даривший мне Любовь и Ласки.

## Сөю кошы

Күкрәк читлегендә Сөю кошы,
Очар урын тармы?!
Күңел диңгезендә кораб йөзә,
Миңа урын бармы?!

Чишеп җибәр читлек бавын,
Очсын Сөю кошы!
Бу дөньяда без җырлыйсы
Сөю җыры шушы.

Төнге диңгез, алсу офык,
Маяк утлар яна.
Дөнья гизеп сиңа килдем,
Көем, моңым яңа.

Таң атканда күрерсең син
Су өстендә җилкән.
Ак җанымны җилкән итеп,
Ул мин сиңа киләм.

## Птица любви

В груди, как в клетке, бьется пташечка любви.
Да ей там, верно, тесно?!
А в душу — гавань заплывают корабли,
Но в ней так мало места!

Откройте дверцу и снимите путы с ног,
Чтоб песню птица пела.
Она взлетит, и к солнцу светлый голосок
Польется очень смело.

Ночное море и янтарный горизонт
С сигнальными огнями.
Из кругосветки я пришла в твой тихий порт
И песнь пою стихами.

Я парусник любви, плывущий на заре,
И альбатрос летящий.
Я белый парус-душу распахну тебе,
Чтоб песню спеть без фальши.

*** * ***

Кочак түгел, йөрәгеңә
Керәм ялкын булып.
Яшрен яну, сагну-утлар
Калыр синдә тынып.

Якын килмә, дип дәшсәң дә,
Бу сүз, беләм, ялган.
Синең Сөю сандугачтай
Дәште алсу таңнан.

Үз-үзеңне алдамачы,
Беләм, сизәм, күрәм.
Шашып мине яратасың,
Мин җаныңа керәм.

*** * ***

Син, йолдызлар телен беләм, дисең,
Ни сөйләвен искән җилләрнең.
Синең шашкын хисләр тибрәткәндер
Сандугачның моңсар телләрен.

Яшь тупылга кунган сандугачкай
Әйтеп сайрый синең үткәнең.
Кайгыларның беркөн бетәчәген,
Бәхет кайда күбрәк үскәнен.

Син тормышны бөек иткән көчне,
Мәхәббәтне илдә күрәсең.
Дөнья күзләреннән яшермичә,
Бүгенгәчә сөям, диясең.

* * *

Не в объятия, а в сердце
Вихрем пламенным влечу.
В доме, где томится скука,
Я зажгу свою свечу.

Тихо скажешь мне: «Не надо!»
Знаю — это ложный тон.
Соловьем и звездопадом
Я любви услышу стон.

Ты в плену самообмана,
Но меня не обмануть.
От любви ты будешь пьяный,
Я найду заветный путь.

* * *

Ты говоришь, что знаешь язык далеких звезд.
И то, о чем болтает шальной бродяга-ветер.
Все чувства, что нахлынут и захлестнут всерьез,
В аккордах птичьих трелей, что льются на рассвете.

На тополиной ветке соловушка вещал,
О том, как боль и беды твои уйдут однажды.
О прошлом и грядущем по нотам сообщал,
Как ты отыщешь счастье, чтоб утолить им жажду.

Великой силы жизни, любви и красоты
Истоки ты находишь в родной своей отчизне.
И миру ты объявишь с восторга высоты,
Любить не перестанешь вовеки в этой жизни.

* * *

Куркам димә очрашудан
Ялкын-учак белән.
Күбәләктәй талпынасың
Кайнар утка, беләм.

Куркам димә хисләремнән,
Кердем төшләреңә.
Былбыл булып сайрар өчен
Кунам түшләреңә.

Кыргый идем, тансык идем,
Көткәнеңне белдем.

Үз-үземнән оялсам да,
Бүген сиңа килдем.

* * *

Кояш суккан башларыңа
Мин күләгә булыйм.
Телисеңме, күңелеңдә
Буран булып дулыйм?!

Йә дулкындай кагылыйм әле
Күңел ярларыңа.
Сайрыйм мәллә таң атканда
Кунып талларыңа?!

Урын тапмый шашкан җаным
Очса читлегеннән,
Рухым табар сине танып
Тарих битләреннән.

* * *

Не говори, что встреч боишься
С бушующим костром.
Я знаю, ты в огонь стремишься
Беспечным мотыльком.

Не говори, что чувств боишься.
Я в снах к тебе приду.
Я соловьем прерву затишье
В заснеженном саду.

Дикарки долгожданной буйства
Ты, знаю, будешь ждать.
Стесняясь и себя и чувства,
Спешу к тебе опять.

* * *

Чтобы в жару тебя укрыть,
Я буду твоей тенью.
А хочешь, я к твоей душе
Примчусь в снегах метели.

Или, как волны к берегам,
Примкну к твоим коленям.
Иль на заре твой сладкий сон
Встревожу птичьей трелью.

И места не найдет душа,
Из клетки улетая.
Найду следы твои, судьбы
Историю листая.

* * *

Кояш ярты юлда әгәр
Туктап калса беркөн,
Күздән аккан яшьләремне
Туктаталмас беркем.

Син күрдеңме, пар күгәрчен
Очып алга төште?

Ничек итеп юраргa да
Белмим күргән төшне.

Күгәрченнәр бер-берсенең
Томшыгыннан үпте.
Юк, үпмәде, томшыгыннан
Татлы шәраб эчте.

Шашып сөю хисләреннән
Буран дулый җанда.
Мин бәхетне эчәм бүген
Кушып кыргый балга.

* * *

Никогда на полдороге
Солнца не остановить.
И никто мне не прикажет
Слезы лить или не лить.

Видишь, — голубь и голубка
Сели вдруг передо мной?
Сна волшебного значенье,
Пробуждение, открой.

Прикоснутся клювом к клюву —
Так у них заведено.
Не целуются голубы –
Пьют любовное вино.

Я проснусь и в одночасье
Разбужу метель свою:
В дикий мед вмешаю счастье
И нектар любви попью.

* * *

Төштә күрдем, өннәремдә
Очрамачы миңа.
Былбыл булып җанга кунган
Бәхетемне кума.

Үрелмә син сөю тулы,
Назлар тулы җанга.
Килми синнән аерыласым,
Атлыйм яңа таңга.

Кичер, дисең, сөю кушып
Газап эчергәнгә.
Рәнҗемим мин алтын көздә
Язлар кичергәнгә.

Кичер, дисең, мәхәббәткә
Кушып бирсәм кайгы.
Сагыш тулы күңелемдә
Шомырт яфрак ярды.

Көнләшеп, син чәчәкләрнең
Өзә күрмә таҗын.
Бергә әйдә каршылыйк без

Якты Сөю таңын.

Күзләреңнән яшьләр түгел,
Тамсын бары бәхет.
Синең белән узган мизгел
Ул — гомерлек тәхет.

* * *

Я видела во сне. А наяву
Мне не встречайся.
Влетевший в душу соловей
Не гонит счастье.

Ты не тянись испить бокал
Любви заветной.
Мы расстаемся. Я иду
К другим рассветам.

Ты говоришь: «Прости, что дал
Испить страданье».
Не злюсь. Мне осенью весна
Дарит свиданья.

Ты говоришь: «Прости, что нёс
С любовью горе».
Черёмуха с тоской души
Цветами спорит.

Ревнуя, не губи цветы,
Не рви соцветий.
Давай вдвоем встречать любовь
Рассветом летним.

Не слезы мы прольем из глаз —
Поток признаний.
Короткий миг — вот наш Олимп,
Итог скитаний.

* * *

Очрашуның кыска гына
Шушы мизгелендә
Ничә тапкыр төшеп мендек
Тарих төпкеленә.

Сагышларны юган дулкын
Кага ике ярга.
Мин сөенәм тормышымда
Якты Сөю барга.

Җылы сүзем белән назлап
Кагылам синең җанга.
Кыргый хыял әйди һаман
Безне алга, алга.

Сөю җыры мәңгелек ул,
Беләсең бит син дә.
Мең рәхмәтле синең белән
Очраштырган көнгә.

Син кабызган якты йолдыз
Балкып яна күктә.
Безнең Сөю мәңгелекме,
Азга, әллә күпкә?!

Күз саласым килми бүген
Хыял аръягына.
Тыңламыйча алга чаба
Тойгы-атлар гына.

* * *

Мы в этот светлый миг
Короткой нашей встречи
Спускались сотни раз
В историю и вечность.

Смывали волны грусть,
Плескались в руслах наших.
Как хорошо, что жизнь
Любви подносит чашу.

Я лаской нежных слов
Души твоей касаюсь.
В порыве за мечтой
Лечу и испаряюсь.

Ты знаешь, гимн Любви
Нам вечно петь дуэтом.
Тот день, что свел с тобой,
Благодарю за это.

Ты звездочку зажег,
Что светит каждый вечер.
Как назовем любовь?
Короткой, долгой, вечной...

На заливных лугах
Мечтам моим раздолье,
И чувства к ним бегут.
Бегут вперед, как кони.

* * *

Син йөрәккә шигырь белән кердең,
Шигырь белән өздең үзәкне.
Әй, сунарчы! Биек кыя таудан
Йөрәккә ук аттың төзәпме?!

Син йөрәккә кердең Назлар белән,
Кабатланмас якты Моң белән.
Сине үткән гасырдан ук инде
Шигырь аша танып мин беләм.

Син йөрәккә кердең Сагыш булып,
Иң татлысы ап-ак сагышның.
Син күңелем кылларыннан тамган,
Җырлар итеп язар табышым.

* * *

Ты стихами вошел в мое сердце.
Рвал душевные струны стихами...
Эй, охотник! Ты с горной вершины
Мое сердце стрелами ранил.

Ты и лаской вошел в мое сердце, –
Светлой, пламенной, неповторимой.
Я тебя много лет уже знаю
По стихам твоим легкокрылым.

Ты и грустью вошел в мое сердце, –
Сладкой, терпкой и белоснежной.
Ты напевом души моей льешься.
Ты изюминка песни нежной.

* * *

Син — бүгенге көнем минем,
Киләчәгем һәм үткәнем,
Гасыр кичеп яши-яши
Өметләнеп гел көткәнем.

Таңнар, гөлләр, җырлар аша
Син бит кердең минем чорга.
Һәм үзең дә әйләндең син
Минем өчен яңа җырга.

Утлар булып кабындың син
Иң караңгы төннәремдә.
Яфрак булып шауладың да
Чәчәк аттың көннәремдә.

Күккә чөйдең, биеклеккә,
Ал кояшның нәкъ үзенә.
Чагыласың балкыш булып
Язмышымның күзләрендә.

* * *

Ты мой светлый сегодняшний день,
Мое прошлое и грядущее.
Я вхожу в века нового тень,
Лишь надеждой живущая.

Через песни, цветы и зарю
Ты вступил в мое время новое.
Обернулся ты в песню мою,
Стал мелодией новой и словом.

Ты как пламя горишь для меня
Ночью темной и мглистою.
Ты цветами зацвел в моих днях,
Стал травою и листьями.

Ты возносишь меня на руках
Прямо к алому солнцу.
Ты рассветом сияешь в глазах,
Льешься светом в оконце.

* * *

Кайнар иреннәрең арган җанны назлый,
Бетәм, янам, көям.
Әйтерсең лә бүген мин беренче тапкыр
Ярны шашып сөям.

Эри наздан җаным, кайный каным,
Сыймый тамырларга.
Дучар булдым дәрья дулкынына
Кушылып агуларга.

Акылымнан шаштым, ахры, аңны
Җуям тиздән.
Җаным тетрәп куя назлар кушып
Әйткән һәрбер сүздән.

Җитәр инде, димен, ишетмисең,
Син — Хыялый гашыйк.
Кайнар утта эреп беттең бугай
Хисләр артык ташып.

* * *

Горячие губы ласкают, как пламя,
Погасшую душу. Я воспламеняюсь.
От искры любви, пробежавшей меж нами,
Впервые в безумную я превращаюсь.

Я таю от ласки. Бурлящим потоком
Кипит моя кровь, не вмещаясь в сосудах.
И я, подчиняясь, плыву от истока
По воле теченья на гребне бурунов.

Я в страстном порыве сознанье теряю,
Рассудок теряю, немного глупею...
Трепещет душа, — я над миром летаю.
От каждого нежного слова я млею.

Я крикну: «Все! Хватит!» Но ты не услышишь.
Безумный влюбленный, ты меры не знаешь.
В любовном огне, что взмывает все выше,
Ты чувства, как я, через край разливаешь.

## Уяну

Уф, дисәм, авыздан ут чыкты,
Төтене күренде еpактан.
Син булдың кайгыда көлдергән,
Көлгәндә үксетеп елаткан.

Берсүзсез буйсындым мин сиңа,
«Кер», — дисәң, кердем ут эченә.
Ышандым, ни генә булса да,
Ялкыннан коткарыр көченә.

Ихтыяр ныклыгын сынадың.
Салкын су сиптең син, кабынсам.
Ташлап та, тагып та йөрмәслек
Язмыштан бирелгән муенсам.

Еландай сихерле карашың
Биетте кыздырган табада.
Кылычтай үткен тел, тибрәлеп,
Тоз сипте төзәлмәс ярага.

Ничә ел мин сиңа кол булдым,
Хисләрне санадым сөюгә.
Өзелдем өлгергән җиләктәй,
Карашың тәнемә тиюгә.

Үзең дә күнектең уенга,
Бирмәдең һичкайчан ятларга.
Минем дә уйга да килмәде
Башкага керфегем кагарга.

## Пробуждение

Ты будто колдовал с огнем,
Мой огнедышащий дракон:
Мог рассмешить печальным днем,
Смех обратить в застрявший ком.

Безмолвно подчинялась я:
Приказывал — я шла в огонь
И верила, спасет меня
Твоя могучая ладонь.

Мог словом холод нагонять,
До пят обдав меня водой.
Тебя ни бросить, ни продать —
Задаром дарен ты судьбой.

Колдующий змеиный взгляд
За пляской смерти наблюдал.
Соль в раны сотый раз подряд
Язык твой острый подсыпал.

Рабой была я столько лет,
Я спутала любовь и страсть.
Цветущий сад извел на нет –
Плодам из чрева не упасть.

Придумал правила игры,
Мне до сих пор их не понять,
Чтоб не могла я до поры
Других кокетством завлекать.

Газап та, ләззәт тә кичердем,
Ирле дә, ирсез дә тормадым.
Җылытмый башлады җанымны
Ялганнан сырылган юрганың.

Кинәттән ачылды сукыр күз,
Абынып егылгач саламга.
Гайбәткә төренеп җил керде
Беркөнне безнең дә арага.

Ничә ел буена син мине

Җылыттың үзеңә кирәктә.
Хыянәт пычагы кададың
Мәхәббәт яшәгән йөрәккә.

Җансыз җан адашты аерылып
Вулкандай кайнаган тәнемнән.
Мин беләм, дошман да сөенмәс
Бүгенге аяныч хәлемнән.

Аудым мин җилләрнең куенына,
Сынганга таяныр терәгем.
Аллаһның кодрәте беләндер
Ярылмый түзде бит йөрәгем.

Егылдым аяктан, шулай да
Өметем торгызды кул сузып.
Төн узгач барыбер көн туа,
Таң ата офыкта сызылып.

Все было: горечь и вина,
Мученье, сладость, миражи.
Жила ни с мужем, ни одна
В лоскутном одеяле лжи.

Но вдруг весна над головой
Взметнула ветром теплый луч:
Пахнуло молодой травой,
Блеснуло солнце из-за туч.

На протяженье многих лет
Меня держал в кольце оков.
Трехгранный выточил стилет,
Чтобы убить мою любовь.

И на костре твоих измен
Душа из тела ввысь рвалась.
Мой враг, чтоб встала я с колен,
Проявит жалость, а не власть.

Мне ветер бурю обещал,
Опору выбил из-под ног.
Но парус сердца охранял,
Наверно, милосердный бог.

Чтоб я держалась на ногах,
Надежда руку мне дает.
Что ж, утро в солнце и цветах
Ночные краски зачеркнет.

## Мизгел

Ак каеннар башын иеп
Искән җилдә чәчен тарый.
Урман-йортта юмартланып
Кәккүк безгә гомер саный.

Бу илаһи гүзәл мизгел
Язлар саен кабатлана.
Һәрбер куак кошка — тәхет,

Мәхәббәтен аңлатканда.

## Мгновения

Сняв с головы наскучивший парик
Снегов, березы кудри разметали
По ветру. И года нам посчитали
Кукушки. А весна на краткий миг

Подснежники рассыпала под ноги
Деревьям. Заливались соловьи,
Выплескивая в небеса восторги…
В тот миг, когда признались мы в любви.

## Көч

Була мизгел, үз-үзеңне хәтта
Күтәрергә көч юк аякта.
Ялгыз күңел, таянырга теләп,
Терәк эзли өзелеп шул чакта.

Тау-ташларны кайчак иңгә салып
Үргә менәр көчләр табыла.
Бер караштан йөрәкләрдә җанны
Балкытырлык ялкын кабына.

## Сила

Бывает миг, когда себя поднять
И в руки взять бывает очень сложно.
Душа на части рвется, чтоб понять,
Где в одиночестве найти опору можно.

Взвалив на плечи жития гранит,
Я силы нахожу подняться в гору.
Твой взгляд, — душа как факел возгорит,
И в сердце вспыхнет отсыревший порох.

## Тылсымлы көй

Кайнар сулышыңны тойган чакта
Һәр күзәнәк тәндә уяна.
Шашкын хисләр диңгезенә салып
Тибрәтәсең татлы хыялда.

Син — гармунчы, ә мин — гармун теле,
Тылсымлы көй — безнең мәхәббәт.
Акылларны җуйдырырлык мизгел,
Җанда сөю, җанда мең ләззәт.

Ике ялкын бер учактай янсын,
Сүрелмәсен иде гомергә.
Бәхет тәмен татып китәр өчен
Очрашканбыз икән без җирдә.

## Волшебная мелодия

В миг, когда рядом дыханье твое,
В теле откроется каждая клетка.

В море бушующих чувств поплывем,
В неге качаясь, как птицы на ветке.

Ты — гармонист, я — гармони душа.
Наша любовь — колдовские напевы.
И безрассудство кружит не спеша,
Выпустив в нас наслаждения стрелы.

Чувства заставят гореть и искрить,
Ввысь устремится любви нашей пламя.
Чтобы успели мы счастье вкусить,
Встретились мы у судьбы под часами.

*** * ***

Үлчәп булмый микъдарларда
Яратуның серле көчен.
Мин сөюдән яралганмын,
Сөелер һәм сөяр өчен.

Үлчәп булмый чакрымнарда
Озынлыгын гомерләрнең.
Яши-яши төшенәсең
Мизгелләрнең кадерләрен.

Үлчәп булмый бәхетләрне
Бизмәннәргә салып һич тә.
Минем бәхет миндә яши,
Үз җанымда булган көчтә.

*** * ***

Нельзя измерить вспышкой света
Любви мерцающую зыбь.
Я рождена любовью этой,
Чтоб быть любимой и любить.

Нельзя измерить в километрах
Весь путь, начертанный судьбой.
Живем, но тают в жизни недрах
Мгновенья дымкой голубой.

Нельзя на вес измерить счастье,
Весам доверив миг и год.
Оно в моей всесильной власти.
Оно в душе моей живет.

## Ике бөртек энҗе

Башларымны салсам иңнәреңә,
Җиңел булыр кебек яшәргә.
Синең көчең җитми, «Кил яныма!
Мин — синеке!» диеп дәшәргә.

Шуны сиздем әле менә бүген,
Мин көчлерәк икән үзеңнән.
Мөлдерәмә ике бөртек энҗе
Тәгәрәде шулчак күземнән.

## Две крупицы жемчуга

Голову кладу тебе на плечи,
Кажется, что жить мне стало легче.
«Я тебя в беде не подведу!», —
Этих слов давно в надежде жду...

Только вдруг заметила сегодня:
Я сильней тебя и благородней.
Две слезы, как жемчуг, на прощанье
Падают из глаз моих печально...

## Яратасым килә

Наз тулгаклый. Җанда бер мизгелдә
Сөю туа кабат яңарып.
Күктә йөзә бәбиләгән болыт,
Җиңеләеп киткән, агарып.

Җилләр булып сиңа пышылдыйм мин,
Ишетәсең микән сүземне?!
Бар дөньяны оныттырыр итеп
Яратасым килә үзеңне.

Уттан алып, суга сала торган
Мизгелләр дә була гомердә.
Синең җанда учак кабызырга
Әйләнимме утлы күмергә?

## Хочу любить

Вздрогнула от нежности. И в душе в момент
Чувство ласки трепетной родилось.
Лик младенца в облаке, солнца свет —
Это сердце на небо вознеслось.

Ветра дуновением я тебе шепчу.
Интересно, слышишь ли ты меня?
Я про все на свете забыть хочу,
Лишь бы ты любовью меня пленял.

То в костер, то в омуты нас бросает жизнь.
Нас ведут мгновения в даль дорог.
Ты огонь в душе своей поддержи!
Хочешь, я подброшу свой уголек?

## Наз

Наздан эри күңел. Әйтерсең лә
Бозда уйный кояш камчысы.
Елтыр энҗе булып мәхәббәтнең
Йөрәгемә керде тамчысы.

## Ласка

Душа от ласки ожила,
Как льдинка, что играет с солнцем.
Блестящей капелькой вошла

Любовь в сердечное оконце.

* * *

Назлардан югалттым башымны,
Шайтанның коткысы көчлеме?
Языкмы, бүләкме язмыштан,
Өнемме, әллә соң төшемме?!

Таң атып килгәндә син дә мин
Гөнаһның куенына атылдык.
Тотмады итәктән нигәдер
Елларда сыналган сабырлык.

Этәрдең җанымны упкынга,
Булдымы ныклыкка сынавың?
Үкенмим, ул мизгел басты бит
Җанымның назларга сусавын.

* * *

Потеряла голову от ласки,
Наважденье чертово сильно?
Дар судьбы, или в грехе увязла?
Явью, или сном оно дано?!

Ты да я у жизни на исходе
Кинулись в объятия греха.
За подол не удержали годы.
Сдержанность на деле так лиха!

Опрокинулась душа с обрыва,
Стойкость не подвластна мне уже.
Не жалею: те мгновенья срыва
Жажду утолят в моей душе.

## Сәгать

Сәгатемә бүген нидер булган,
Минутларны саный кирегә.
Минем сагынуга түзә алмый
Китермәкче сине бирегә.

Сәгать булып, сәгать аңлый хәлем,
Саный ярсу йөрәк тибешен.
Әзсенәдер ул да безгә тигән
Язмышларның татлы өлешен.

## Часы

Часы мои считают время вспять...
Что происходит не могу понять?
Возможно, возвращают наши встречи
В холодный дом и этот грустный вечер...

И маятник заглушит вой тоски,
Что сердце разрывает на куски.
Часы готовы сладость наших встреч

В другом отсчете трепетно беречь.

## Бер җылы сүз

Күңел — сабый. Сөю-назга мохтаҗ,
Олыгаеп инде килсә дә.
Бер җылы сүз җитә күтәрергә
Көчең җитмәс йөкне җилкәдә.

Бер җылы сүз канат куя иңгә,
Тылсым өреп гүя яшәртә.
Бар дөньяны якты нурга күмеп,
Йөрәккә дәрт өстәп яшәтә.

## Одно теплое слово

Душа — ребенок ласку ожидает,
И повзрослев, нуждается в любви.
Из теплых слов мне одного хватает,
Чтоб вынести все тяготы земли.

Из теплых слов одно дает мне крылья,
Вдыхает в душу молодость, как маг.
Его луч света рассекает мрак,
И сердце вверх взмывает птицей сильной.

## Болытлар

Болытлар да күңел кошы сыман.
Арадашчы итик аларны.
Көн дә күкне гизгән хәбәрчеләр
Якынайтсын безнең араны.

Ак болытлар елмаюым булса,
Күксел болыт сагыну-сагышым.
Тып-тып тамса яңгыр, хәтерләтер
Ярсу йөрәгемнең тавышын.

Мин сагынсам, болытларга карыйм,
Сәлам юллап синең тарафка.
...Синнән килгән болыт эленеп калган
Өй янында үскән наратка.

## Облака

Облака, как птицы нашей души,
Это посредники, судьи верховные,
Путешественники в небесной тиши,
Те, что сближают пути духовные.

Облако-дымок, — мой веселый нрав,
А в свинцово-серых, — тоска-печаль.
Если дождь польет, — значит ты не прав,
Это сердца звук дробью застучал.

Перистым пером напишу привет,
В строчке облаков если скучно мне.
... Облако твое, что послал в ответ,
Под моим окном спуталось в сосне.

## Сиреньнәр

Назга сусап арган зифа буйны
Көчле куллар алды кочакка.
Тетрәнде җан, килеп эләккәндәй
Дөрләп янган кайнар учакка.

Утлы караш сихерләде кинәт,
Тукталгандай булды йөрәге.
Шуып төште йомры иңбашыннан
Тәнгә ятып торган күлмәге.

«Җаным минем, бердәнберем!» — диеп
Кабатлыйлар кайнар иреннәр.
Тәрәз каршысында хуш ис бөркеп
Оялышып тора сиреньнәр.

## Сирень

Стройное тело скучало без ласки.
Сильные руки его приподняли, —
Вздрогнули струны души и уж в пляске
Чувства, как искры костра, засверкали.

Огненным вихрем твой взгляд проникает
В сердце мое, что стучится несмело.
А по плечам тихо платье стекает,
Освобождая прекрасное тело.

«Сердце мое! Ненаглядная пери!», —
Сладко горячие губы шептали.
Взгляд от окна отвернула сирень,
Чей аромат мы страстно вдыхали.

## Кичер мине

Кичер мине, сөюемне саклап,
Гомер буе уйлап яшәгәнгә
Төшләремдә өзгәләнеп эзләп,
Өннәремдә күргәч дәшмәгәнгә.

Кичер мине, озын төннәремдә
Сагынганга иркә-назларыңны.
Гаепләмәм, ак кышларда кабат
Кайтаралсаң якты язларымны.

Кичер мине, ап-ак бураннарда
Эзләп йөрим баскан эзләреңне.
Күңелемдә назлы бер җыр итеп
Саклыйм синең әйткән сүзләреңне.

## Прости меня

Прости меня, что, сохранив любовь,
Всю жизнь жила лишь мыслью о тебе.
Что в ленте снов найти пыталась вновь,
А наяву не нахожу нигде.

Прости меня, что под покровом тьмы
Без нежности грустила и ждала.
Не буду обвинять, коль из зимы
В весну меня вернешь, чтоб ожила.

Прости меня, что в круговерти вьюг
Ищу следы, как прежде, на снегу.
И душу греет песня ласки рук,
И нежность слов забыть я не могу.

*** * ***

Әллә нишләп үзгәрде бу дөнья,
Тоныкланды, кинәт каралды.
Яшәр өчен яралып та җанда,
Туалмыйча төште ялралгы.

Үлде сөю, бүген гүргә керә,
Ялгыз гына укыйм җеназа.
Сакламаган, хакламаган өчен
Аллаһ бирә икән мең җәза.

Читлектә кош. Ул бит минем йөрәк,
Сайравыннан тынган сандугач.
Җырын сузар, язгы җилләр исеп,
Күңел кылларына кагылгач.

*** * ***

Почему-то изменился мой мир:
Потускнело все вокруг, почернело.
Зародившийся в душе к жизни пыл
Не родился, скинут был неумело.

Тело сгинувшей любви вгоним в гроб.
Я за упокой молитву читаю.
За небрежность — справедливый урок:
Дал Господь мне тысячу наказаний.

В клетке птица. Это сердце мое.
Соловью не петь отныне в неволе.
Заунывно ветер песню поет
В день весенний, арфе внутренней вторя.

## Бала елый...

*(Поэма)*

Яшьлек гүзәл... Ә шул гүзәллекне
Саклый алабызмы мәңгегә:
Кем югала юлда очрап упкын,
Кем сыгылмый биек үр менә...

...Алсу йөзле, кара бөдрә чәчле,
Зифа буйлы гүзәл сылуга

Әзерләнгән каһәрләнгән сөю —
Шулдыр сәбәп канат сынуга.

Гармун тотып каршы атлый егет.
Кыйгач кашлы, үткен карашлы.
Шулмы әллә гомерлеккә тиңе,
Шулмы аның пары, җанашы?!

Кайдан тойсын уналтысы тулган
Гөнаһсызлык корган тозакны.
Яшь күңелгә ургып сөю керде,
Ачкычларсыз ачып йозакны.

Сөйде шашып, дөньясын онытып,
Тик гармунчы булды уенда.
Ә «насыйбы» күптән башка белән
Биегән шул кызыл туенда.

Яшьлек — җүләр. Гашыйк күзе сукыр,
Соң ачыла күңел күзләре.
Кыз алданды, әче ачынуның
Яра булып калды эзләре.

## Плач ребенка...

*(Поэма)*

Прекрасно детство... Как такое счастье
Мы сможем пронести и сохранить?
Обрыв — и у кого-то рвется нить,
А кто-то вверх несет через ненастье...

Румяное лицо и волос смоль...
Стройна, красива юная девица.
Но крылья ей сломает, будто птице,
Греховной ласки сладостная боль.

Вот парень-музыкант... И ведь каков!
Красив, кудряв и взгляд, как небо, синий!
Вдруг это он, вторая половина,
Единственная светлая любовь?

Откуда знать ей! Ей всего шестнадцать!
Святую плоть держала под замком,
И вдруг, — любовь влетела сквозняком
В сердечко без ключей, чтоб там остаться.

Любила страстно, пылко, всей душой,
О нем лишь были чаянья и мысли...
А суженый на свадьбе веселился,
На собственной, с невестою другой.

Как просто молодым попасть в аркан.
Глаза влюбленных лишены прозренья.
Любовь, ты, как колючее растенье,
Оставила следы от рваных ран.

Китте яры. Ул аныкы түгел:
Гаиләсе, нәни улы бар.

Ә яшь Сылу аның өчен бары
Гади курчак — уйнап сөйгән яр...

Япь-яшь кызның башын әйләндереп,
Намусын да буяп карага,
Хушлашмый да бер көн китеп барды
Гаиләсе торган калага.

Сылу калды тапталган гөл сыман,
Саргаеп һәм көеп, сулыгып...
Яшәр өчен газап кочагында,
Күз яшенә ялгыз кол булып.

Ярасыннан саркый йөрәк каны,
Карынында тибә баласы.
Кеше күзләренә ничек багар...
Бәхилләрме газиз анасы?

Канатлары сынды очар кошның,
Барыр юлын томан каплады.
Адашкан җан тормыш тозакларын
Ачар өчен ачкыч тапмады.

Нинди өмет аны алдап йөртте,
Җан иңгәнче шушы сабыйга?
Ана булу олы бәхет, диләр,
Ник соң Сылу тоташ кайгыда?

Кача-поса ят күзләрдән кызый,
Бала туар көнне көткәндә,
Аңлап алды: теләсә дә ничек,
Юллар ябык икән үткәнгә.

Ушел он, сгинул, навсегда растаял.
Есть у него ребенок и семья.
Сылу была лишь куклой. На семь «я»
Ее разбил, в любовь, шутя играя.

Девчонке юной голову вскружил,
Окрасив совесть грязно-черным цветом.
И укатил, как катится монета,
Не попрощавшись, в город, где он жил.

Сылу осталась брошенным цветком,
Что сохнет и желтеет под ногами,
Чтоб жить за кадром в душной мелодраме,
В плену страданий слезы лить тайком.

Ей боль сердечной раны не унять.
Растет живот, пинается ребенок...
Но встречных взгляд так холоден и колок,
И сможет ли простить родная мать?

Сломались крылья юного птенца,
Ему уже над миром не подняться.
Лишь по земле придется ей скитаться,
В ловушку угодив судьбы-ловца.

Обманчива надежда, что потом,
Когда душа в ребеночка вселится,
Любовью материнской насладится...
Но у Сылу в душе такой надлом.

Так, прячась от чужих недобрых глаз,
Она ждала рождения ребенка
И понимала, рвется нитью тонкой
Любовь с названьем «временная связь».

Вөҗдан газапларын баса алмый,
Күз яшьләре битен юса да,
Рәнҗетелгән сөю җәза булып
Көтә аны алда — тупсада.

Төнлә белән, тулгак тоткан чакта,
Әрнүләрдән кысып тешләрен,
Ышык эзли подвал ишегеннән,
Бәрә-суга ташка тезләрен.

Аңы томаланды ямьсез уйдан.
(Ахры, инде шашты акылдан...)
Башына да килми, ул адымга
Барса, нәрсә көтә ахырдан?

Алда чарасызлык, алдау чире,
Җәмгыятьнең черек нигезе...
Йотар төсле бала белән бергә
Тормыш дигән баткак диңгезе...

Бала белән бәйләп торган кендек
Җебен чәйнәп өзгән анага
Үз каны да акыл иңдермәде —
Нәни бала салды хафага.

Туды бала. Күңел тулы сагыш,
Сайлап алган ачы язмышы...
...Соңгы көнгә кадәр иярәчәк
Арттан калмый кылган ялгышы.

Буталды бар дөнья, җир убылды,
Белешмәде кеше үз-үзен:
Җанын иблис суырып алган ана
Бәреп ватты вөҗдан көзгесен:

Страданья невозможно погасить
Горючими, обильными слезами.
Обиделась любовь и в наказанье
Ей приказала так на свете жить.

В ту ночь, когда пришлось держать ответ,
От боли и страданий стиснув зубы,
Она в подвал ползла в укрытье сруба,
Содрав колени, не включая свет.

Но мысли роем кружат в голове.
Казалось, грань безумья где-то рядом.
И с горем безутешным нету сладу:
Еще лишь шаг, — и все, она на дне.

Как дальше жить? Что уготовит новь?
Гнилой остов общественного мненья
Проглотит их с ребенком, без сомненья,
И засосет болотной жизни топь.

Ни нить, что мать с ребенком единит —
Оборванная в родах пуповина,
Ни крови зов ее родного сына

Сылу уже не могут вразумить.

Родился мальчик, светлая душа,
Но мать судьбу ему готовит злую,
Где горе, уготованное всуе,
Жестоко сдавит плечи малыша.

Не стоит ошибаться в этот час.
Судьбу ребенка, горькую, как зелье,
И ей нести рубашкою нательной.
Жизнь не прощает малодушный фарс.

Чүп савытын тәүге бишек итте
Яңа туган сабый балага.
Төн карасын томан алыштырды,
Пәрдә корып ике арага.

Бала елый... Үрсәләнеп елый,
Эзли имчәк — ана күкрәген.
Шушы аваз җиһан җанын тырный
Һәм сызлата җирнең йөрәген.

Этләр урап алды чүп савытын, —
Юаталмый алар нәнине,
Өзгәләргә әзер булсалар да
Чүпкә бала салган «әни»не.

Тиле ана чәчен җилләр йолкый
Аңлатырга теләп хатасын:
Җаны барлар чүпкә ташлап качмый
Җанны ярып туган баласын!

Кача ана әллә баласыннан,
Әллә кача үзе үзеннән.
Белми әле — алда көткән җәза
Авыррак сырхау, үлемнән.

Колагында яңгыраган тавыш —
Үзәк өзгеч бала елавы...
Гасырга тиң озын чирү-газап —
Алда яшәячәк еллары.

Бала елый... Җиһан үкси... Үкси...
Әй адашты сөю, адашты.
Дөнья күзе бага галәм аша
Акылыннан язган карашны.

Мир кружит человека, как волчок,
И он, теряясь, не находит места.
Мать душу отдала на откуп бесам,
Ребенка бросив в мусорный бачок.

Предутренний туман сменяет ночь,
Как занавес меж нею и ребенком...
Мальчонка ищет грудь и плачет громко,
Что даже Матери-Земле невмочь.

Примчалась свора бешеных собак,
Пытаются младенца успокоить
И разорвать на части ту, что сорит
Дитем своим, его бросая в бак.

Вцепился ветер в космы на бегу

Рвет их, желая объяснить ошибку:
«Для малого ребенка место в зыбке!
Я от невзгод его не сберегу!»

Но мать бежит. Возможно от себя,
А может, от ребеночка родного.
Еще не зная, рок ей уготовил
Расплату, что ни с чем сравнить нельзя.

Страшней болезни, смерти и разлук
В ушах звучит надрывный плач ребенка.
И рвет на части сердце, перепонки...
Ее везде настигнет этот звук.

Скрип дерева, вой ветра, снегопад, —
Доносит плач. Потерянная ласка,
Сквозь Божий глаз вселенской мудрой маски,
Сознанье гложет, будоражит взгляд.

Шашынган күз чүп савытларыннан
Актарынып эзли баласын.
Җил сызгырып арттан куа килә
Тирәнәйтеп йөрәк ярасын.

Бала елый... аның саен ана
Кызулата атлар адымын.
Бер савыттан бер савытка чаба,
Табар төсле гүя сабыен.

Таныгандай итеп, теш ыржайтып,
Этләр үтә өреп яныннан.
... Нигә Аллаһ аны җирдә йөртә,
Аермаган нигә җаныннан?!

Бала елый... Туфан купканда да
Басылмастыр елау тавышы.
Үткән еллар, узган юллар аша
Телә җанны сабый каргышы.

Безумная, наперекор судьбе
Ребенка ищет в мусорных завалах,
И подгоняет ветер-завывала...
Как горько, но ребенка нет нигде.

Вновь слышен детский плач. За годом год
Бежит Сылу быстрее и быстрее,
Она еще надеется и верит,
Что вот сейчас она его найдет...

Рычат собаки, зубы обнажив,
С презрением спешат ее покинуть:
«По воле Бога ей пора бы сгинуть!
Зло на земле не может долго жить!»

Плач малыша все кружится в тиши.
Он не исчезнет. Он взмывает выше...
И мир сквозь годы с содроганьем слышит
Проклятье детской брошенной души.

* * *

Дөреслекнең йөзе нинди була,
Балкый микән якты кояш төсле?
Әллә инде чагыла дөньялыкның
Гасырлардан җыйган сагыш төсе?!

Дөреслекнең тәме нинди була,
Татлыракмы пешкән алмалардан?
Әллә инде бөтен дөньялыкның
Хәсрәт ачыларын җыеп алган?

Дөреслекне табып була микән...
Дөреслекне танып була микән...

* * *

Какое лицо у правды?
Сияющее, как солнце?
А может, в тоске вселенской
Мерцает звездой в оконце?

Скажите, а вкус правды
Вкуснее ли яблок спелых?
А может, в ней горечь страданий,
Что мир вкусил неумело?

Можно ли правду познать?
Можно ль найти и узнать?

## Моңлы язмыш

Мин дөньяга туган чагымда ук
Туганмындыр моңга уралып.
Моңлы язмыш тәкъдир тарафыннан
Куелгандыр алдан юралып.

Сандугачлар моңы сеңгән талдан
Әткәй үргән миңа бишекне.
Ак теләкләр тели-тели, Әнкәй
Дөньялыкка ачкан ишекне.

Ялантәпи атлап киткәч җирдән,
Бәбкә үлән биргән моңнарын.
Иркен ялан кочагында аунап,
Җанга салдым моңын кылганның.

Боргаланып аккан инешнең дә
Йөрәк тойды челтер тавышын.
Мәңгелеккә җуймый саклар өчен
Сеңдергәнмен барлык сагышын.

Авылымның һәрбер урамының
Миңа ачык һәрбер ишеген,
Хәтер сандыгында барлый-барлый
Тибрәткәнгә күңел бишегем.

Моңнар белән тулы минем язмыш,
Моң түгелә һәрбер шигырьгә.
Әле ярый моңсыз булып яшәү
Язылмаган минем гомергә.

## Светлая грусть

Когда я только-только в мир вошел,
Меня окутал он своей печалью.
Тоскливо жизнь плыла по воле волн:
Был черным челн, был путь по начертанью.

Отец из ивы сплел мне колыбель.
Она, плакучая, впитала птичьи плачи.
Желаньем светлым в мир открыли дверь,
Но жизнь, возможно, думала иначе.

Я шаг за шагом по земле ступал.
Набрал морщинок от гусиных лапок.
Мне ветер в поле душу обнажал.
Я ковылем заваливался набок.

Струилась неподдельная тоска,
Как вьется ручеек с журчащим всхлипом,
И море серебрится у виска,
Где память бьет прибоем и приливом.

Мне щедро каждый дом откроет дверь,
И прошлого сундук перебирая,
Качаю колыбель своих потерь.
Мои печали каждый понимает.

Вся наша жизнь пронизана тоской.
Из каждого стиха она струится.
Возможно, и не нужен мне покой,
Коль в этом мире мне пришлось родиться.

## Сандугач

Тал-тирәккә кунып сайрый
Бер кош һәр көн таң тугач.
Әйтерсең лә һәр күңелдә
Сайрый сары сандугач.

Һәр йөрәкнең үз ярасы,
Һәр кошның бар үз моңы.
Һәр кешенең язмышында
Тәкъдир язган үз юлы.

Кошка — тирәк, җанга йөрәк
Кирәк гомер итәргә.
Сусаганда чишмә булсын
Ятып суын эчәргә.

Кем ярасын кем дәвалар,
Җанга тоташ моң тулгач?
Җиргә килгән һәрбер кеше
Ул — яралы сандугач.

## Соловей

На ранней зорьке птаха меж ветвей
Поет во славу дня на всю округу.
Живет и в наших душах соловей,
Он раны сердца лечит нам, как другу.

У каждой птицы свой мотив тоски.
Жизнь каждого из нас — своя соната.
У птиц и у людей свои пути:
Простор для птиц, душевность людям надо.

Терпенье — вот основа бытия.
Когда душа болит, но жаждет жизни —
Струится песня, родником звеня,
И утоляет жажду, лечит мысли.

Кто может излечить чужую боль?
Лишь тот, кто сам испытывал страданье!
Живущий на земле играет роль
Подранка, что поет нам утром ранним.

* * *

Ком бураны, кар бураны, язмыш бураннарына
Саташып кереп адаштым йөргән
сукмакларымда.
Нихәл итим,
күңел гөлем шиңде бит кыраулардан,
Кемнәр кереп алып чыгар,
аралап бураннардан?!

* * *

Песчаная, снежная буря, житейская буря...
В такой круговерти дорогу найти не могу я.
Что делать? Души моей майский цветок
прихватили морозы.
Так кто же укажет мне путь
сквозь ветра и заносы?

* * *

Дөньяны аңларга,
Дусларны барларга.
Сыгылмый, бөгелми,
Сер бирми ятларга,
Сайлаган сукмактан
Тайпылмый атларга.
Тапканны югалтмый
Кадерләп сакларга.
Өр-яңа җыр булып
Яшәргә бу җирдә.
Өйрәттең. И, тормыш!
Урадың мең сергә.

* * *

Разгадывать мир и друзей обретать,
Не кланяясь и не сгибаясь.
Не дать свои тайны чужим разгадать.
Идти, но с пути не сбиваясь.
Все то, что нашла, в суете не терять.
Сберечь сокровенные чувства.

Жизнь — песня познанья. Ее исполнять
Должны мы на редкость искусно!

* * *

Чиксез галәм киңлегендә
Һәммәбезгә үзгә дөнья.
Җиргә басып йөрсәк тә без,
Җир язмышы безнең кулда.

Беләбезме кадерләрен
Ходай биргән бу бәхетнең?
Үз кулыбыз белән әллә
Уябызмы җир-ләхетне?!

Тынып тормый гасырлардан
Гасырларга сугыш уты.
Яна-яна ярлылана
Бар халыкның уртак йорты.

Адашырлык урманнар юк,
Уңдырышсыз җирләр арта.
Муенына элмәк салып
Һәр замана бавын тарта.

Кешелекнең кулларында
Җир-Ананың җаны көйри.
...Гамьсез кеше берни күрми,
Җиргә ныклап басып йөри.

* * *

В пространстве галактических широт
У каждого из нас есть свой мирок.
Мы ходим лабиринтами дорог,
Шагами измеряя жизни срок.

Нам недоступна ценность бытия
И счастья, что нам дарит мудрый Бог.
И вот уже проложена стерня
Своим серпом, и сложен личный стог.

Земля объята заревом войны.
Горит, горит наш беспокойный век.
И пепелищем стал наш общий дом,
Где костровым назначен человек.

Сплошь просеки на теле у лесов,
В пустыни превращаются поля…
Вскачь гонит время. В цокоте подков
Не слышим, как волнуется Земля.

Она страдает, сжатая рукой
Безжалостного деспота — людей.
А мы ликуем и чиним разбой,
Не становясь ни чище, ни добрей…

## Яшь

Кояш нуры җылытканга түзми
Ачыла бөре, үлән калыккан.
Ялгыз күзлим язгы манзараны,
Каен елый, елый аклыктан.

Татлы яшьләр ага кәүсә буйлап,
Минем яшьләр нигә ачы соң?
Тәкъдирләргә язган ялгызлыкның
Юып бетереп булмый ачысын.

*** * ***

Хыял дәште ерак офыкларга,
Балкып янды өмет йолдызы.
Кендек каны тамган туфрак тартты,
Авылында калды җир кызы.

## Слеза

Когда под ласкою лучей
Бутон набухнет в травке вешней,
С березы катится ручей
Медово-сладких слез безгрешных...

Я ж соль и горечь лью украдкой.
Их подсластить не суждено:
Мне одиночество закладки
Вложило в жизнь давным-давно.

*** * ***

Мечта, вздыхая, увлекала в даль,
Где от меня звезду надежд не прячут тени.
И свет она набросит, словно шаль,
На плечи дочери Земли — деревни.

## Буталган язмышлар

*(Поэма)*

Мин күрдем чын сөю үрнәген
Бик яшьтән, авылда чакта ук.
Сәйдәттәй яшәде елмаеп,
Эчендә булса да тоташ ут.

...Өзелеп яраткан егете
Ярәште беркөнне Сәйдәне.
Әйтерсең язмышлар бер-берсен
Чәчләрдән чәчләргә бәйләде.

Иң сылу, иң эшчән яшь хатын,
Учында тиенне биетә.
Бәхеттән шашынган чагында
Китә ул тыпырдап биеп тә.

Мирхәйдәр — бердәнбер кояшы,
Киләчәк бәхете, өмете.
Кыз туып, яшьлекнең вәгъдәсен
Мәңгегә йөрәккә беркетте.

Яшь хатын, сөйкемле яшь ана
Нур чәчә җиһанның йөзенә.
Җан сөйгән яр белән янәшә
Керер күк гомере көзенә.

Сөеп һәм сөелеп туймаслык,
Киң җилкә — ышыклар ире бар.
Сәйдәнең бәхете түгәрәк,
Күңлендә юк сагыш, юк бер зар.

## Запутанные судьбы

*(Поэма)*

Я видела пример большой любви —
О ней в деревне каждый говорит.
Сайда сверкала солнцем изнутри
Так, будто в глубине огонь горит.

Влюбилась в паренька, любовь пришла,
И он однажды к ней прислал сватов.
Навеки их судьба переплела,
Как волосы косичек-колосков.

Трудолюбива, хороша жена,
Легко в работе кружит, как волчок.
Когда от счастья кругом голова,
Припустит в пляс, да руки на бочок.

Подарком в дом от солнечной любви,
В знак будущего счастья дочь вошла.
Рожденьем клятву их соединив,
Ростком надежды в сердце проросла.

Свет материнства лучиком добра
В глазах сияет мамы молодой,
И молодости вечная игра
По радуге уводит за собой.

Под боком мужа, за его плечом
Любовь, как речка звонкая, бежит.
И бьется счастье у Сайды ключом:
Печали нет, нет жалобы на жизнь.

*** * ***

Галәмнең иге юк, чиге юк.
Болытлый кайвакыт күкләр дә.
Күкрәүдәй таралды шомлы өн,
Айнымый торды бик күпләр дә.

Ил белән түктеләр күз яшен,
Сугыш ул — ач үлем, дәһшәтле.
Кешелек сыйдырмый аңына
Кан түккән, җан кыйган вәхшәтне.

Дошманнар таптыйлар намусын,
Кырларын, урманын илемнең.
Меңәрләп сугышчы бер булып

Каршылый зур яуда үлемен.

Авылда калдылар карт-коры,
Зарлы гамь тулы бар сарайлар...
Барсы да фронтка! Ил өчен
Көч түгә бабайлар, малайлар.

Хатын-кыз җигелде арбага,
Көн белән кара төн ялгана.
Икенче фронтта хатын-кыз
Ир булды ул чакта заманга.

Ирләре фронтта. Хатыннар
Утырып хат яза кичләрен.
Таң нуры сызылган вакыттан
Башлыйлар иртәнге эшләрен.

* * *

Жизнь свои волны катит без границ
Бескрайним галактическим путем.
Но тучи, словно стая грозных птиц,
Гром, молнию, беду приносят в дом.

Дурные вести кружат над страной:
Кровавой птицей взмыла вверх война.
Груз горя разум не вмещал людской:
Кровь, смерть, страданья, беды, седина.

Враг топчет сапогами честь страны.
Леса, поля в бушующем огне.
На поле брани Родины сыны
Объединили силы в той войне.

Вмиг опустело, как амбар, село:
Кто мог, ушел с фашистом воевать.
Всех мужиков метлою подмело, —
Остались стар, да мал, да женщин рать.

Вот бабы и взялись за тяжкий гуж.
Так пашут, что слились и день, и ночь.
Работают, пока воюет муж,
Победе надо чем-нибудь помочь.

И письма пишут вечером на фронт,
Собравшись вместе в чьей-нибудь избе,
Уставшие от тягот и забот.
А утром — вновь по кругу бег в узде.

Фронтта кызганмый үз-үзен,
Ирләре кан коя ил өчен.
Ә язмыш мең төрле сынауда
Газаплый тылдагы җан көчен.

Бәхетле тормышның ядкаре —
Сәйдәгә калган җан җимешен
Ач үлем урлады бер көнне,
Аңламый нигә соң, ни өчен?!

Өзелде кызының гомере,
Терелә алмады сырхаудан.
Җирләргә ятып җил елады,
Сынма дип, Сәйдә-гөл, сынаудан.

Өмете көч бирде яшәргә:
Бик тиздән кайтыр дип бөркете.
Шул өмет чаткысы яшәтте,
Бәгырьнең сызлавын киметте.

Мирхәйдәр кайткачтын ямарлар
Сугышлар туздырган ояны.
Туасы балалар башыннан
Сыйпады Сәйдәнең хыялы.

Сәйдә бит җаваплы ил-көнгә,
Бригадир эшен ул башкара.
Эчендә кайнаган ялкынны
Яшерә, сиздерми башкага.

Хат килсә фронттан, балкый ул,
Йөзендә мең кояш елмая.
Әйтерсең шатлыгы нур сибә
Үзенә һәм бөтен дөньяга.

Лицом к лицу защитники страны
Встречаются со смертью и с врагом.
А в тыл, как тени грозные войны,
Несчастье и беда влетают в дом.

Той жизни довоенной огонек,
Напоминанье счастья — дочь Сайды,
Смерть поглотила, как голодный волк.
За что такой ей поворот судьбы?!

Вмиг оборвалась тоненькая нить,
И выходить дитя никто не смог.
И плакал ветер: «Ей бы жить, да жить,
Но у цветка сломался стебелек!»

Что помогло Сайде перебороть
Удар судьбы и в горе устоять?...
Надежда — сокол милый у ворот
Появится, чтоб силы ей придать.

Вернется Мирхайдар, и вместе с ним
В гнезде сумеют дыры залатать.
Головки гладит детушкам родным
В мечтах о счастье будущая мать.

Оплачивает пред страной долги,
Работа в бригадирах, ох, трудна.
А боль потери, что гудит в груди,
Упрячет так, что людям не видна.

Ждет от родного мужа письмецо.
Глядь, промелькнет улыбкой солнца луч.
И озарится радостью лицо,
Он пишет ей: «Ты жди, и я вернусь».

Кабатлап укый ул хатларны,
Йөрәге суыктан туңганда.
Гел алга ашкына күңеле,
Карамый яңгырга, буранга.

Җиңүгә илткән һәр адымны
Атлыйлар ил белән күмәкләп.
Сизгәндәй ул көннең киләсен
Май башын иркәли күбәләк.

*** * ***

Гөжләде бар авыл: карты да,
Яше дә елады шатлыктан.
Килде бит зур Җиңү бар илгә,
Бүләк ул бәһасез вакыттан.

Чәчәкле май ае китерде
Дөньяга шатлыклы хәбәрне.
Кешелек күңлендә ул шатлык
Яралы Җир шары кадәрле.

Кайталар аяксыз-кулсызлар,
Кайталар фронттан батырлар.
Күрешү мизгеле җиткәнгә
Сөенеп, игеннәр калкырлар.

Сәйдәнең күңеле — очар кош,
Җәяүләп йөгерде юл буйлап,
Шатлыгы эченә сыймыйча,
Бер җырлап, бер көлеп, бер елап.

Пристаньда бар халык.Сәламләп
Пароход гудогын кычкырта —
Гел кайгы түгел ул, шатлык та
Җыр булып килә бит тормышта.

Она его читает по стократ,
А сердце бьется, запертое в клеть.
Мечта летит сквозь тысячи преград,
Сквозь град и дождь,войну, разлуку, смерть.

Прошла Сайда к победе со страной
В едином, несгибаемом строю.
С надеждой в сердце: «Обрету покой,
В начале мая птичкой запою».

*** * ***

Гудит деревня вместе со страной.
От радости и счастья столько слез!
Подарок долгожданный, дорогой –
Великую Победу май принес.

Цветами устилает путь весна.
Над миром кружит радостная весть.
И раны те, что нанесла война,
Залечит. В каждом сердце, их не счесть.

Приедут победители домой.
Вернутся с фронта, кто без рук, без ног.
Все не беда, а счастье: ты живой,
Ты устоял, родимый колосок.

Душа Сайды, как ласточка кружит,
Бежит она босая вдоль дорог.
На сердце радость трелями звенит,
А смех и слезы водят хоровод.

На пристани волнуется народ,
Свист пароходный полнит неба синь.
Здесь каждый счастья, а не горя ждет:
Вновь песней звонкой в дом вернется жизнь.

Иң газиз, кадерле кешесен
Ул алыр бик тиздән кочаклап.
Янарлар наз булып бергәләп
Мәхәббәт кабызган учакта.

Чү,таныш гәүдә бит, бик таныш...
Бер хатын куенына сыенган.
Теленде Сәйдәнең бәгыре —
Мәхрүмме Сөюнең сыеннан?!

Иренә ни булган? Башкага
Сузган ул көчле, нык кулларын.
Ә бәлки, сугышта бергәләп
Үткәндер зур фронт елларын?

Кул түгел, күзе дә ятларның
Күзенә өзелеп текәлгән.
Ишетми, күрми ул, Сәйдәнең
Карашы аңа бит инәлгән.

Тетрәде кинәттән бар җиһан,
Гүя җир убылды, югалды.
Уздылар танымый яныннан,
Сәйдә соң җиңәрме томанны?!

Мәңгегә бергә дип кавышкан
Ярымы китте ул ятларга?!
Утлы көл сулышы сибелде
Вәгъдәгә, бирелгән антларга.

Родной и близкий едет человек,
Его обнимет с радостью она.
Их чувства вспыхнут новизной. Вовек
Большой любви не потушить костра.

Стоп! Это он,…но кто же там сидит
В объятьях, на коленях дорогих?
Оторопело сердце у Сайды
В сомнениях, предчувствиях плохих.

Что с мужем приключилось? Он другой
Подставил свое сильное плечо?
А может быть, дорогой фронтовой
Прошли и новый сделали отсчет?

Не узнает... Любовью полон взгляд,
Которым на чужую он глядит.

Его глаза о многом говорят.
И он не видит нежный взгляд Сайды.

Как будто вспышка молнии внутри,
И почва уплывает из-под ног:
Они, не замечая, мимо шли.
Туман Сайде всю душу обволок:

«Свою семью и свой счастливый дом
Создали и клялись всю жизнь любить.
Да все война спалила, и углем
Засыпан путь, чтоб с милым не ходить».

* * *

Авылга борылып кайтканда,
Иярде сыгылган шәүләсе.
Алдыннан томанга төренеп
Атлады иренең гәүдәсе.

Йөрәккә сабырлык сыенган,
Иренә гаеп тә атмады.
Сугыш дип барсына гаепле,
Күңленнән кичерде, аклады.

* * *

Нур чәчкән гөл сыман Маһинур,
Карасаң, туймаслык караплар.
Битләре ай кебек балкыса,
Кояштай яндыра карашлар.

Ничекләр сөймәсен Мирхәйдәр
Язлардай ачылган чәчәкне?!
Шушы гөл үлемнән коткарды,
Терелтте, су сибеп яшәртте.

Аңлавын аңлады Сәйдәсе,
Сөюе чынлап та хак икән.
Язмышны, бәхетне сугышның
Каралган ирене «пәп» иткән.

Ачу юк Сәйдәнең күңелендә,
Исән бит сөйгәне, ул яши.
Күргәндә баш түбән иелә,
Сәйдәгә ялгыш та сүз дәшми.

* * *

В деревню возвращалась, словно тень,
А за спиной, как призрак, шла беда.
Два силуэта уходили в сень
Тумана, исчезая в никуда.

Любовь на сердце не хранит обид
И на любимого не копит зло.
Войну во всем ей следует винить, —
Душа переживет, пусть тяжело.

* * *

Как лучезарный цветик — Магинур,
Кто взглянет — глаз вовек не отведет:
Лица сиянием затмит луну,
Лучистым взглядом сердце обожжет.

Да как же Мирхайдару не любить
Бутон прекрасный, что расцвел весной,
От смерти спас, смог душу оживить,
Омолодить своей живой водой!

Так женским сердцем поняла Сайда
Любви великой красоту и пыл.
Лишь ей война несчастье поднесла —
Погас очаг семьи, надежды — в пыль.

Нельзя держать обиду за душой:
Любимый жив, пусть долго он живет.
Зря избегает, ходит стороной,
Сайда случайно словом не кольнет.

Яралы йөрәкләр сүзсез дә
Аңлады язмышның сынавын.
Сугышта ярылган бомбалар
Көйдергән канатын хыялның.

Дуслары күченде шәһәргә,
Кайберсе чиксезлек иленә.
Ә Сәйдә сөйгәне бәхетенә
Куанып яшәүгә сөенә.

Кояшны сүндерми җил-яңгыр,
Ул көн дә бер калка, бер бата.
Маһинур бүләге иренә —
Тупырдап үсүче биш бала.

Ал кояш нурлары үрелеп
Сәйдәнең йөрәген җылыта.
Күршедә үсүче биш кызчык
Биш бүләк аңарга тормышта.

Шуларны сөеп ул юана.
Аптырый балалар кайчакта:
Чулпылар елаша моң сибеп,
Алганда аларны кочакка?

Перәннек, кәнфиттән өзми ул,
Кызларга һәрвакыт ягымлы.
Килсәләр, капканы ачуга
Мул итеп әзерли табынны.

Урамны урый ул көнгә ун,
Бәлки, дип, очрар сөйгәне.
Беләме «пожарный» ялгыз өй
Эчендә Сәйдәсе көйгәнне?!

Без слов зияют раны на душе,
Разрывы бомб оставили свой след.

Нет в сердце крыльев. Им не быть уже…
Их опалил огонь военных лет.

Подруги разлетелись, кто куда:
Кто к детям в город, кто-то в мир иной.
Лишь о любимом думает Сайда,
Вот встретит раз и оживет душой.

Жизнь, будто солнце по небу, идет.
Не изменить планетам их осей.
Так мужу радость Магинур несет:
Ему рожает пятерых детей.

Луч солнца извивается в садах,
Обогревая душу у Сайды.
Так девочки с улыбкой на устах
Вошли подарком в дом ее судьбы.

Она ласкает девочек, а те
От рук ее умчаться норовят.
Надкосники слезой звенят Сайде,
Монетки песней вместе с ней грустят.

Девчушек угостит, накроет стол,
Приветливо откроет дверь в свой дом.
В ее руках конфеты — хлеб да соль,
Чтоб встретить на пороге, на своем.

По улице по десять раз на дню
Она идет в надежде встретить вновь
Непозабытую любовь свою.
Так изнутри сжигает дом любовь.

Шакката авылның кешесе,
Аптырап хатынның хәленә.
Һаман да ялгызы яши ул,
Төренеп чуклы ак шәленә.

Нинди уй кичерә? Түгелгән
Яшьләрнең шаһиты бары өй.
Яңгырый тәрәздән кичләрен
Ялгызлык яздырган моңлы көй.

Көнгә тик бер генә күрсә дә,
Рәхмәтле булды ул язмышка.
Үпкә сүз әйтмәде иренә,
Рәнҗетеп күңелен ялгыш та.

Күңелне үксетеп нигә соң
Сайрамый башлады сандугач?!
Дөньялар тын калды, Мирхәйдәр
Сулыгып кинәттән авыргач.

Сәйдә дә түзмичә әрнүгә
Юл тотты Мирхәйдәр өенә.
Чит ишек тоткасын тартканда,
Селкенми калды бит миңе дә!

...Ятакта газизе. Бердәнбер.
Гомерлек бәхете, тәхете.

Өзелер гомере бик тиздән,
Казылыр, алыныр ләхете.

Бәхиллек бирергә килде ул
Өзелеп яраткан иренә, —
«Ул тиеш күчкәч тә бакыйга
Бары тик оҗмахка керергә».

Дивится деревенский наш народ
Терпению. Сайду всем очень жаль.
Уж сколько лет она одна живет,
Укутав горе в кружевную шаль.

Но мысли криком по ночам кричат,
Да скрипом половиц рыдает дом.
И грустную мелодию свеча
Ей пишет воском на сердце пустом.

А днем она судьбу благодарит,
Что дарит встречи редкие порой.
Нет. Мужу горьких слов не говорит,
Чтоб не нарушить милого покой.

Но смолк однажды в роще соловей,
И тишина тревогой замерла.
Вдруг Мирхайдар, что песня жизни всей,
Внезапно и серьезно захворал.

Сайда не может боль в себе сдержать,
И в дом к нему решается войти.
Лишь замерла на миг, щеколду сжав,
Не шелохнулась, чувствам вопреки.

Вот он, ее единственный, лежит,
И царь, и бог, повенчанный судьбой.
Но рвется, рвется тонкой ниткой жизнь
Уходит от Сайды он в мир иной.

Простить, благословить его пришла,
Он мужем ей остался дорогим:
«Пусть в светлый рай летит его душа,
Пусть ангелы закружатся над ним!»

Ым какты Мирхәйдәр. Сәйдәсе
Иелде йөзенә иренең,
Сыйпады мамыктай бармаклар
Сугышның сылаган сөремен.

«Бәхил мин барсына, кадерлем,
Син мине иттең дип тәхетле.
Әгәр син булмасаң дөньяда
Аңламас идем чын бәхетне.

Тыныч бул, сөеклем! Соңгы кат
Тыңла син әйтәсе сүземне!
Тик сугыш гаепле барсына,
Каплады бәхетне сөреме.

Мин риза-бәхилмен язмышка,
Тыныч бар Аллаһы каршына.
Рәнҗетеп яшәдем дигән уй

Кермәсен чаларган башыңа».

Күзләрдә соңгы чык тамчысы,
Мирхәйдәр куллары кулында.
Озатты тол хатын сөйгәнен
Мәңгелек, чиксезлек юлына.

Кояшы сүндеме, шул көннән
Ямь тапмый башлады тормыштан.
Әйтерсең кадерле кешесе
Кайталмый калган зур сугыштан.

Ялан һәм кырларга чыга да
Эзли ул сөйгәне эзләрен.
Тасмадай юлларга текәгән
Талчыккан, нур сүнгән күзләрен.

Стон... и умолк навеки Мирхайдар.
Сайда склонилась горестно над ним.
Сжимала пальцы ватные, как дар,
Посыпанный золою дар войны.

«Простила все, любимый, я тебе,
За то, что ты в царицы превознес.
Не будь тебя, — не знала б я в судьбе
Любви бескрайней и счастливых грез.

Да будет мир, покой душе твоей.
Скажу, как перед праведным судом:
Подстреленною птицей на войне
Упало счастье, не влетев в наш дом.

Я не в обиде на жестокий рок,
И не держу обиду на тебя.
Иди туда, где милосердный Бог,
Без тяжких дум. Он ждет тебя любя».

И слезы, будто капельки росы,
Катились горько на сплетенье рук.
Вдова. К несчастью, лезвием косы
Смерть подлая, лишь добавляла мук.

Укрыла мир тоски кромешной тьма,
И радость жизни навсегда ушла.
Как будто и не кончилась война,
Желанного назад не отдала.

И безутешно ищет милый след
Сайда и тенью бродит по лугам.
В глазах ее усталых тусклый свет
Надежды, что отыщется он там.

Көтә ул иренең кайтканын,
Үзәге өзелеп, тилмереп.
Авылда сүз чыкты, Сәйдәттәй
Йөри дип саташып, тилереп.

Хаклык бар халыкның сүзендә,
Кояшы сүнде шул Сәйдәнең,

Югалткач томанда мәңгегә
Яшьлеге сузган гөл бәйләмен.

Олы юл чатында тол хатын
Каршылый сөйгәнен сугыштан...
Кайтмады. Сыгылды зифа гөл,
Өзелде саташып тормыштан.

Юл кочып ятучы корбанның
Җил сыйпый таралган чәчләрен.
Җил сөртә тузанлы йөзеннән
Эз салган иң соңгы яшьләрен.

* * *

Маһинур үстерде биш кызын,
Җирләде ирен һәм Сәйдәне.
Ә җаны тартыша һәр мизгел,
Әллә соң ычкынмас бәйдәме?!

Ничекләр яшәргә тормышта?
Тормыш бит какмады, сукмады.
Беркайчан сул якка борылып
Йөртмәде читләргә сукмагы.

Как раньше, возвращенья с фронта ждет,
Страдает и изводится сама.
В деревне шепчет за спиной народ,
Что, видимо, Сайда сошла с ума.

Молва людская, как всегда, права.
Погасло солнце ясное Сайды.
Туманом принакрылась голова,
Завяли прошлой юности цветы.

Вновь на большак идет встречать вдова
Любимого, желанного с войны.
Он не вернулся... Сердце, как листва,
Оборвалось и кружится в пыли.

Безжизненна…В ногах свернулся путь.
И ветер нежно волосы чесал.
Он сглаживал следы морщинок — пут.
Он пыль и грусть стирал с ее лица.

* * *

А Магинур растит своих девчат,
Похоронив и мужа, и Сайду.
И лишь душа трепещет каждый час:
С цепи бы не сорваться на беду.

Она не знает, как ей дальше жить,
И хоть судьба не била и не жгла:
Любви нектар преподнесла испить,
И выпила она его сполна.

Фаҗига төйнәлгән язмышта
Санады гел үзен гаепле.
Ничекләр юарга җандагы
Мәхәббәт каргышын, гаепне?!

Түзмәде беркөнне йөрәге,
Ярылды җан телгән сагыштан.
Биш кызы — дәвамы — дөньяга
Бүләге буталган язмыштан.

Кызлары таралды ул киткәч,
Очтылар балалар еракка.
Өч кабер янәшә, өч язмыш
Каеннар шаулаган зиратта.

* * *

Язмышның иң соңгы карары:
Нигезне ут алды беркөнне.
Көл белән буталды нигез дә,
Сакламый хәтердә беркемне.

Авылның хәтере бик тирән,
Онтылмый буталган язмышлар.
Буш калган нигезләр кисәтә:
Булмасын дөньяда сугышлар.

* * *

Мин күрдем чын сөю үрнәген
Бик яшьтән, авылда чакта ук.
Кешелек хәтерен яңартып
Мәйданнар түрендә яна ут.

Тяжелый узел, что сплела война,
Не сгладить и теперь не развязать.
Она считала, в том ее вина,
Что у Сайды любовь смогла отнять.

Скрипело сердце, и рвалась душа.
Сплетенная лоза рождает гроздь:
Пять дочек, будто ягоды с куста.
Подарок в жизни, поднесенный в дождь.

Так с этим грузом и ушла она…
Похоронили дочки, разбрелись.
Три жизни. Три могилы. Тишина.
И кружит над погостом желтый лист…

* * *

Вглядимся в этот поворот судьбы:
Как бы крепка опора ни была,
И глубоки фундамента столбы,
Все беспощадно выгорит дотла.

В деревне память очень глубока.
Она хранит истории людей.
Чтоб не погасло пламя очага,

Мир берегите над планетой всей.

* * *

Я видела великую любовь.
О ней в деревне каждый говорит.
И вечным светом память будит вновь
Огонь, что в центре площади горит.

## Хәтер җебе

Бөтерелеп ап-ак карлар ява,
Әйтерсең лә чәчәк сибелә.
Күбәләктәй очып килеп куна
Чия төсле пешкән иренгә.

Хәтер җебе чая яшьлегемә
Кайтыр өчен янә юл ала.
Мизгел үтми, уттай кайнарлыктан
Кар бөртеге эреп югала.

## Нить памяти

Кружится, падает снег белоснежный –
Белая россыпь цветов мне под ноги.
Чувство, что бабочка крылышком нежным
Трогает губы цветка-недотроги.

Тонкие нити смешливого детства
Память протянет вдоль кромки дороги.
Мчатся мгновения, а приглядеться –
Тают, как снег, что ложится под ноги.

* * *

Кабат тусаң әгәр, язмышыңны
Үзгәртерсең микән? Бу сорау
Күңел кылларына бәрелүгә
Чыңлап куя, гүя кыңгырау.

Ничек итеп җавап бирим сезгә,
Язмышымны нигә үзгәртим?!
Һәр кешенең үз урыны җирдә,
Сезнең кебек түгел, үзгә мин.

Үз ялгышым үзем төзәткәндә
Сөенәм мин сабый шикелле.
Нәни генә шатлык кичерсәм дә,
Күккә чөям моңлы күңелне.

Үз максатым, үзем яулар үрем,
Үзем генә җырлар җырым бар.
Җәйдә явам тансык яңгыр булып,
Көздә яфрак, кышта ап-ак кар.

Язмышымны нигә үзгәртергә?
Үксез бала түгел мин җирдә.

Гомер йомгагымны үзем сүтәм,
Чорный-чорный җебен моң, сергә.

* * *

Представь: тебе пришлось родиться вновь...
Изменишь ли судьбы предначертанье?
Вопрос влетает в жизнь, как звездный дождь,
Как в колокол набата клокотанье.

Что вам ответить на вопрос такой?
Менять судьбу? А так ли это важно?!
Мы по земле идем своей тропой.
Вот я иду открыто и отважно.

Ошибки исправляю я сама
И радуюсь, как маленький ребенок.
И счастье, пусть глоток, я пью до дна.
Парит душа, как трепетный галчонок.

И к цели в жизни я приду сама.
Спою мотив, лишь мне одной знакомый.
Я дождь желанный летом, я весна,
Я листопад, я снег прозрачный, скромный.

Так для чего судьбу свою менять?
Я ж не ребенок взбалмошно-капризный.
Клубок дорог сумею размотать,
Чтоб из него связать рисунок жизни.

* * *

Чык та төшеп өлгермәгән әле
Балачагым баскан эзләргә.
Болын җиле йомшак кулы белән,
Песи баласыдай сырпаланып,
Иркәләнеп сарыла тезләргә.

Шул ук кояш балкый күк йөзендә,
Нурын сирпеп алсу гөлләргә.
Зәңгәр томан булып урала да,
Язмыш булып кабат юрала да,
Сагыш сеңә үткән көннәргә.

Әле яңа ялантәпи басып
Үткән идем яшел чирәмнән.
Кай арада көмеш пәрәвезләр,
Соңгы җиле булып җылы җәйнең,
Күбәләктәй оча тирәмнән.

Гомер үткән, көзгә кереп барам...
Чык тамчысы минем күзләрдә.
Бала чакның якты ал кояшы,
Чуар күбәләкле ямьле җәе
Озата бара алтын көзләргә.

* * *

Не успела окропить роса

Детства след, что вдаль бежит скрываясь,
А беспечный ветер полевой,
Как котенок маленький, ласкаясь,
Трется нежно под моей ногой.

Так же солнце светит в небесах,
Излучая свет на алый цветик.
Синими туманами кружит
И судьбы моей пути наметит,
Где тоска о прошлом ворожит.

Где недавно босоногой шла,
Проходила по зеленой тропке –
Паутинок серебристых нить
Ветер летний «закавычит» в скобки,
Кокон бабочке пытаясь свить.

Жизнь прошла. Вхожу в осенний день…
На моих глазах роса сверкает.
Детства солнце катится в зенит.
Бабочки цветные провожают
В путь, что золотым листом манит.

* * *

Тормыш китабымның һәр битенә
Язмышымны үз кулларым язды.
Үзем иҗат иткән көйне көйләп
Сагышланды моңлы күңел сазы.

Үзем яздым, үзем укый бардым
Һәр җөмләсен, һәрбер яңа сүзен.
Кара төндә арып йомдым да мин,
Таңны күрер өчен ачтым күзем.

Төсле бизәк белән бизи-бизи
Язам әле гомер китабымны.
Ак хыяллар дәшә алга таба,
Сүндермә, җил, гомер учагымны.

* * *

Не пропуская ни одной страницы,
Судьбу свою писала в книге жизни.
Придуманную песню пела птицей,
Что грустно плачет у болотной жижи.

Сама писала и сама читала,
Слова перебирая, предложенья.
Закрыла к ночи я глаза, — устала.
А утром насладилась пробужденьем.

Судьбу цветным узором украшая,
Для книги я слагаю продолженье.
Ввысь за мечтой шагаю не спеша я,
И ветру не задуть мое горенье.

Поэзия Веры Хамидуллиной
*в переводе Альфии Ситдиковой*

**Любовь — красивая мелодия**
**Мәхәббәт — ул гүзәл моң**

## Я открываю свой альбом

Я открываю свой альбом
И улетаю в детство.
Там все не так. Там нет проблем
До боли в сердце.
Там все приятно и светло
И голос мамы рядом,
И праздников переполох,
И чьи-то ласковые взгляды.

Как хорошо открыть альбом
И возвратиться в детство.
Но не спасет от всех проблем
Меня такое бегство.
Увы, увы, мы все рабы
Рутинного угара.
Нас не излечит от тоски
Мелодия из бара.

Но я люблю открыть альбом
И вновь вернуться в детство.
Я вспомню первую любовь,
И детское кокетство,
И поцелуи под луной,
И перебор гитары,
И тихо сердца своего
Послушаю удары.

## Альбомымны ачам

Мин үземнең альбомымны ачам.
Очам ерак балачагыма.
Йөрәк сызмый, бар да башка анда
Һәм урын юк борчуларыма.
Анда бар да яхшы, якты, рәхәт.
Янымда гел әни тавышы.
Бәйрәм мәшәкате, кемнәрнеңдер
Елмаюлы җылы карашы.

Рәхәт миңа альбом битен ачып
Кире кайту балачагыма.
Араламый ләкин борчулардан
Үткәннәргә алай качу да.
Аһ, кызганыч, без бит бары коллар
Узганнарның сөреме эчендә.
Сагышлардан араламый безне
Замананың яңа көе дә.

Яратам мин альбомымны ачып
Узганнарга кабат кайтуны.
Тәүге мәхәббәтем искә алам,

Балаларча кылтаюымны.
Ай астында үбешкәннәремне,
Чирткәләвем гитара кылын.
Йөрәгемдә ярсып чапкан атның
Балачакта калган колынын.

## Мое детство босоногое

Что шагаешь ты за мной,
Мое детство босоногое?
Я забыла про тебя
И иду своей дорогою.

Но когда тоска-печаль,
Обнимаешь душу ты мою,
Хочешь, завтра невзначай
У тебя прощенье вымолю?..

## Ялан тәпиле балачак

Ялан тәпиле балачак,
Ник барасың артымнан?
Мин оныттым инде сине,
Төштем агач атымнан.

Сагыш-моңнар баскан чакта,
Кочасың күңелемнән.
Телисеңме, иртәгә үк
Гафу үтенәм синнән?..

## Разноцветные огни

Разноцветные огни вдоль по улице несутся,
Разноцветные огни, словно козочки, пасутся.
Разноцветные огни мне во тьме мигают дружно,
Почему же я сейчас отношусь к ним равнодушно?
Неужели от меня детство в прошлое уходит
И веселые мечты за собою вдаль уводит?..

## Төрле төстәге утлар

Урам буйлап чаба утлар,
Төрле төсләргә кереп.
Төсле утлар көтүлектә
Йөргән кәҗәләр кебек.
Төн карасын ертып утлар
Җемелдәшеп күз кыса.
Ә мин никтер бу мизгелне
Күзәтәм тыныч кына.
Матур, якты хыялларны
Киереп җилкәннәргә,
Балачагым гүя бүген
Күченә үткәннәргә.

## Кораблики

Я кораблики пускала
По весенним ручейкам.
В детстве я еще не знала,
Что придет конец мечтам.
Я за ними убегала
И махала вслед рукой,
Я резвилась и играла
С непослушною водой.
И я желала плаванья
Большому кораблю.
Казалось, что на палубе,
Качаясь, я стою.
Я верила, что там
Плывет моя мечта,
Любовь, надежда, вера, доброта.

Я кораблик провожала,
Отправляла в дальний путь,
И закрыв глаза, желала,
Чтоб не смог он утонуть,
Чтоб не сесть ему на мели,
Не попасть в водоворот,
И ручей его до цели —
Прямо в море унесет.
И я желала плаванья
Большому кораблю.
Казалось, что на палубе,
Качаясь, я стою.
Я верила, что там
Плывет моя мечта.
Любовь, надежда, вера, доброта.

## Кораблар

Көймә-кораблар агыздым
Мин язгы ташкыннарда.
Хыяллар беркөн сүнәр дип
Килмәде башыма да.
Артларыннан йөгердем мин
Изи-изи кулларны.
Уйный-уйный чабып уздым
Тынгы белмәс суларны.
Мин теләдем зур корабның
Йөзүен ерак-ерак.
Һәм күзаллап палубада
Басып торганны уйлап.
Мин ышандым: ул корабта
Йөзә минем хыялым.
Мәхәббәт, Өмет, Ышаныч,
Игелекле уйларым.

Мин корабны озатып калдым
Бик ерак-ерак юлга.
Күзне йомып, тели-тели
Батмавын тирән суда.
Тимәсен дип төбе комга,
Юлыкмасын чоңгылга.

Илтсен инеше максатка,
Зур диңгез куенына.
Мин телəдем ак юл бары
Шушы зур корабыма.
Палубада торган төсле
Таянып уйларыма.
Мин ышандым, анда диеп
Минем хыялым йөзə.

Мы взрослеем очень дерзко,
Но когда-нибудь потом
Вдруг кораблики из детства
К нам придут волшебным сном.
Обнимая память нежно,
Уведут меня опять
В край, где счастье безмятежно,
Я пыталась предсказать,
Где я желала плаванья
Большому кораблю.
Казалось, что на палубе,
Качаясь, я стою.
Я верила, что там
Плывет моя мечта,
Любовь, надежда, вера, доброта...

Мəхəббəт, Өмет, Ышаныч
Изге уйларны тезə.

Без үсəбез кыюланып,
Ə шулай да яңадан,
Балачак корабы кайтса,
Тылсымлы төш яңара.
Назлап кочып хəтеремне,
Кабат дəшеп еракка,
Алып китəр борчуларсыз
Бəхет яшəгəн якка,
Мин кайчандыр зур корабка
Йөзү телəгəн чакка.
Палубага баскан килеш,
Карап йөзəсе якка.
Мин ышанам, ул якларда
Йөзə хыялым минем.
Мəхəббəт, Өмет, Ышаныч,
Игелек торган илем.

## Школьный бал

Школьный бал. Школьный бал...
В зеркалах танцуют свечи!
Я смеюсь. Я пою.
Ах какой чудесный вечер!
Отчего вдруг слеза на щеку мою упала?
Очень жаль,
что нельзя в жизни все начать сначала.

Мы с тобой пробежим
По бескрайним коридорам:

«До свидания, класс!
Мы к тебе вернемся скоро!»
Но слова, как песок,
канут в бездну, канут в Лету.
Нам в ответ тишина — ни ответа, ни привета.

Через год, через два
Что-то снова повторится:
Тот же зал, тот же класс, но уже другие лица.
И звонок и урок для кого-то, для кого-то...
Да и мне не до вас, у меня свои заботы.

Звуки вальса в ночи,
Глаз твоих сиянье рядом,
Этот зал, этот бал навсегда запомнить надо.
Никогда нам сюда
вместе с детством не вернуться.
Уходя, уходя, постарайся оглянуться.

## Чыгарылыш кичәсе

Чыгарылыш кичәсе бу...
Күзгеләрдә шәм яна.
Мин көләмен, мин җырлыймын,
Мин үзгә бүген, яңа.

Нигә соң кайнар күз яше
Минем керфектән тама?!
Күңел сизә, кайтыр юллар
Ябык үткәнгә таба...

Йөгерәбез җитәкләшеп
Озын коридор буйлап.
«Сау бул, мәктәп, бер кайтырбыз,
Кайтырбыз сиңа урап!»

Сүзләр төпсез чиксезлектә,
Мәңгелектә югала.
Безгә җавап, бу ни гаҗәп,
Бары тынлык тын ала.

Бер елдан, ике елданмы
Нәрсәдер кабатланыр.
Шул ук мәктәп, шул ук залда
Яңа йөзләр яңарыр.

Вальс моңы, төнге тынлык,
Синең күзләр балкышы.
Залны, кичәне мәңгегә
Саклар күңел алкышы.

Балачак белән яңадан
Очрашмабыз беркайчан.
Киткән мәлдә борылып карап
Кул изик аңа чаттан.

*** * ***

Я в горстях несу стихи,
Хороши они, иль плохи,
Эти маленькие крохи
Затерявшейся души.

Из ошибок и потерь
Соткан их узор нехитрый.
Это, как к судьбе моей
Поэтические титры.

*** * ***

Ике учым тулы шигырь.
Яхшымы, әллә начар?!
Адашкан җан валчыклары —
Нәни кош теле кадәр.

Хата-югалтулар аша
Гади бизәк тукылган.
Болар минем язмышыма
Язган шигъри титрлар.

*** * ***

Стих новорожденный на суд я принесла.
И я услышала о нем одни слова.
Мне говорили, что он сер и не подрос,
Что он и слаб, и худ, — порви, сожги и брось.

Он подрастет, окрепнет он, надеюсь я.
И соберутся в этот день мои друзья.
Он все снесет, он вынесет любой позор,
Ведь он еще безумно мал и он не вор.

И он не лжец, и не паяц, и не подлец...
Но вынесен уж приговор — ему конец.

*** * ***

Мин хөкемгә куйдым ак дөньяга
Күзен ачкан сабый баланы.
Һәм ишеттем җилләр пышылдавын:
«Соры кошчык күзли даланы».
Әйтте күпләр йөрәгемне телеп:
«Ташла аны, читкә тотып ат!
Ул бик көчсез, үзе шып-шыр сөяк,
Ерт син аны яки утка як!»
Мин ышанам аның үсәренә,
Ныгыячак аның канаты.
Шул көн җиткәч җыелырлар дуслар,
Аңлап, ничек була ярату.
Ул хәзергә түзә барсына да,
Һәм күтәрә хурлык тамгасын.
Ул чиктән тыш нәни, түгел карак,
Йөзе чиста, кара тапмассың!
Ул ялганчы, шамакай да түгел,
Яман диеп беркем атамас.
Ләкин аңа хөкем чыгарылган:
«Чыпчык бөркет дигән ат алмас».

## Эпиграмма

Эпиграмма.
Лжи ни грамма.

«Нет» — для лести.
«Да» — для чести.
Эпиграмма –
Кому-то яма.
Смех сквозь слезы.
Жизни драма.
Но пустое,
Успокойтесь.
Для кручины
Нет причины.
Нет намека
Здесь на склоку.
Присмотрись
С другого боку.
Это вспышка
Боли сердца.
Гамма чувств
И гнева терция.
Это вызов
Жизни серой.
Это просто
Выпад смелый.

## Эпиграмма

Эпиграмма.
Ялган юк грамм да.
Куштанлык түгел,
Вөҗдан көзгесе.
Эпиграмма —
Кемгә казылма.
Яшь аша көлү,
Драма өлгесе.
Ләкин юк-бар бу,
Тынычланыгыз.
Хәсрәт өченгә
Юк бер сәбәп тә.
Юк бер ишарә
Монда ызгышка.
Икенче яктан
Күз сал тормышка.
Йөрәк сызлауның
Бу бер очкыны.
Хисләр гаммасы,
Нәфрәт дулкыны.
Бу каршы килү
Соры тормышка.
Гади чакыру
Кыю ачышка.

* * *

Мы природу видим и так.
Но сказать о ней в рифму и в такт,
Чтоб душа звенела и пела,
И летела, кружась, в небесах...
Дай бог, чтобы я так сумела
О простом написать в стихах...

* * *

Табигатьнең һәр фасылы якын, үзгә,
Әйтерсең лә салынган ул матур көйгә.
Очсын күңел, зәңгәр күкне иңләп-буйлап,
Ә кыллары торсын чыңлап, торсын җырлап.
Гадилекне салыр өчен шигъри юлга,
Суз син, Аллаһ, каурый каләм минем кулга!

* * *

Льются капли: раз, два, три —
С мокрой ивовой коры.
И бегут ручьи, урча,
По проспекту Ильича.

На трамвай купив билеты,
Едем мы прощаться с летом...

* * *

Таллар елый, тамчы талый
Талларның кайрыларын.
Гөрләвек күзендә күрәм
Җәйләрдән аерылганым.
Трамвай да китеп бара
Хушлашып җәйләр белән.
Минем кулда билет яна —
Көзләрем килә, беләм.

## Рассвет

Заалело небо на востоке.
Засияло разными огнями.
И, как будто солнечный зайчонок,
Солнца луч промчался по поляне.

Солнце, пробуждающее землю,
Показалось робко красным краем.
Интересно: как лесные люди
Солнце повстречали? Мы не знаем.

Что ж, посмотрим, что в лесу творится.
Ох, уж эти птицы-непоседы!
Все кричат, поют, летят куда-то.
Все хотят узнать: что у соседей?

Как грачи гнездятся на березах?
И когда сюда скворцы прибудут?
И вообще-то, новости сороки
На хвосте лесным приносят людям.

Утром все, по-своему, прекрасно:
Соловей, поющий славу солнцу.
И, конечно, ветка ивы гибкой,
По воде пускающая кольца.

## Таң атканда

Көнчыгышта күк алланды.
Төрле төсле утлар балкый.

Әйтерсең лә нур шәүләсе
Үзән иңли йөгерә-атлый.

Җирне уятучы кояш
Кыяр-кыймас ача битен.
Үткәннәргә күз салыйк бер
Чеметеп ачып хәтер читен.

Әйдә карыйк, урман нишли?!
Эх, бу кошлар тынгысызлар.
Теләп барсын белер өчен
Канат кагып җыр сузалар.

Оя кора кара карга,
Тиздән кайтыр сыерчыклар.
Канатында хәбәр ташый
Саесканнар-кыбырсыклар.

Таң атуы гаҗәп гүзәл:
Былбыл җырлый кояшка дан.
Сыгылмалы тал ботагы
Суга иелеп балдак салган.

* * *

Обрывки памяти нанизывает осень
На нити, что прошили жизнь мою.
Возможно, что никто уже не спросит,
Во что я верю и кого люблю.

Лишь для меня самой необходимо
Бежать за уходящим солнцем вслед,
Чтоб на дороге отыскать незримый
Судьбы моей теряющийся след.

* * *

Сәйлән итеп ефәк җепкә тезә
Хәтер ертыкларын көзләрем.
Иманың ни, кемне сөясең дип,
Беркем йөрмәс эзләп эзләрем.

Фәкать үзем өчен йөгерүем
Батып барган кояш артыннан,
Табар өчен күзгә күренмәгән
Язмыш эзен юллар чатыннан.

* * *

Ярко-алая турецкая гвоздика
Отцветала в палисаднике моем,
И любовь моя безрадостно и тихо
Покрывалась лепестками, как бытьем.

Ты ушел. Не позвонил. Не оглянулся.
На прощанье только вскользь поцеловал.
Небосвод холодной осени сомкнулся.
Он любовь мою оплакать обещал.

И дожди слезами стекла обмывали.

И стонали надо мною журавли.
Бабье лето мне вернуть не обещали, —
Предрекали жизнь без счастья и любви.

Ярко-алая турецкая гвоздика
Отцветала в палисаднике моем,
И любовь моя безрадостно и тихо
Покрывалась лепестками, как быльем...

* * *

Ут төсле канәфер чәчәге,
Бакчамда коелды таҗларың.
Сөюем үткәннәр куенында
Каршылар шатлыксыз таңнарын.

Мин көттем, борылып дәшмәдең,
Хушлашып үпкәндә җил булып.
Кушылды күк йөзе күзләргә,
Кайгыдан еларга сулыгып.

Яшь юды тәрәзә өлгесен,
Торналар сагышы күкләрдә.
Әбиләр чуагы кайтмастыр,
Мәхәббәт һәм бәхет үткәндә.

Ут идең, канәфер чәчәге!
Бакчамда коелды таҗларың.
Сөюем хәтергә төренеп
Каршылар шатлыксыз таңнарын.

## Законы осени

Осень раздевается красиво,
Сбрасывая золота наряд.
Почему ж убого и тоскливо
Рощи обнаженные стоят?

На ковре, работе модерниста,
Хочется разлечься и заснуть,
И попробовать дождем напиться,
И по клину угадать свой путь.

Но у осени свои законы:
Ранним снегом, будто сединой,
Засыпает старые каноны,
Открывая вечность в мир иной.

И становятся, увы, не важны
Перспективы будущих побед.
И не хочется уже вальяжно
Шествовать на фоне прошлых лет.

## Көз кануны

Көз чишенә шундый матур итеп,
Алтын шәлен сала иңеннән.

Шәрәләнгән агачлыклар никтер
Сагышланып моңга төренгән.

Рәссам чиккән палас өсләренә
Сузылып яткан яфрак йокларга.
Яңгыр суын бер туйганчы эчеп
Кай сукмакка барып туктарга?!

Көз аеның аның үз кануны:
Кырпак карлар каплый юлларны.
Башка дөнья ишеген ачып куя
Чал вакытның җылы куллары.

Өмет итмим инде киләчәктән
Җиңү бүләк итәр мизгелне.
Кайтып алып булмый үткәннәрдән
Гомер атын тоткан тезгенне.

* * *

У калины кисти красные
До земли спустились низко.
В пору осени ненасытную
Жизнь-дороженька раскисла.

Лишь вода зрачками черными
На меня глядит печально,
И беду пророчат вороны,
Вслед крылом махнув прощально.

Грязь дорог закроет проседью.
Снегом выбелятся волосы.
И зима покончит с осенью,
Скрасив полосы и помыслы.

* * *

Баланнарның кызыл тәлгәшләре
Җиргә кадәр түбән иелгән.
Елак көзнең шушы мәлләренә
Гомер юлым ташып түгелгән.

Суларның да төсе кара-кучкыл,
Сагышлардан күмелә моңнарга.
Баш очымда канат кага козгын,
Тели, ахры, бәла юрарга.

Ак кыраулар каплар юл баткагын,
Кар агартыр безнең чәчләрне.
Кыш килер дә көз гомерен өзәр,
Уйга күмәр ап-ак бәсләре.

* * *

Любовь — красивая мелодия,
В ней ссора — вовсе не пустяк.
Ключом скрипичным какофония
Дверь открывает на чердак.

Там в сундуках с семью печатями
Хранится грязное белье.
Табу, запретом и проклятием
От наших рук ограждено.

Пусть ссора будет пустяковая,
Пусть пробежится холодок,
Но у всего, что там заковано,
Не нужно открывать замок.

* * *

Сөю матур көйгә тиңдәш,
Әйтә күрмә авыр сүзләр.
Өйдә тавыш куба калса,
Чормага юл күңел эзләр.

Җиде йозак элгән сандык
Саклап тора күпме керне.
Табу тыя таратудан
Дөньялыкка сыймас серне.

Үпкәләшсәк юкка-барга,
Арабыздан үтсә салкын,
Ачылмасын бикле сандык —
Өтеп алмас бозлы ялкын.

* * *

Мы на разных берегах,
Нет ни мостика, ни брода.
Мне нет дела до тебя,
Мне милей моя свобода.

Не кричи и не ропщи
На стихию и на случай.
Ты попал, как кур в ощип,
Но поверь, так будет лучше.

Не заламывай в тоске
Похотливых белых ручек,
Мы на разных берегах —
Это мой счастливый случай.

Я мираж, твой сон, твой бред,
Нереальное начало.
Эту сказку про любовь —
Просто речка нажурчала.

Успокойся и прощай,
У меня другие планы,
Ну, а проще говоря,
Я тебе не по карману.

* * *

Без икебез ике ярда,
Күперләр юк арабызда.
Үткәннәрне томан сарды,
Ирек дәва ярабызга.

Кычкырсаң да, зарлансаң да,
Мин ишетмим сине бүтән.
Үзгәрер дип өметләнү
Хата булган икән күптән.

Сагышланып син каерма
Иңеңдәге канатыңны.
Без икебез ике ярда —
Иярләдем пар атымны.

Мин тик рәшәң, татлы төшең,
Чынга ашмас ак хыялың.
Сөю дигән әкият ул
Көйле җыры тар елганың.

Үткәнемдә калырсың син.
Башка тормыш минем алда.
Без икебез ике кеше —
Бушлык яши җанда, аңла.

* * *

У меня к тебе претензий нет.
Будешь уходить, захлопни дверь.
Не бывает счастья и побед
Без утрат, ошибок и потерь.

Я не буду звать тебя в ночи
И молить за все простить меня.
Ночью, хоть моли, а хоть кричи, —
Не найти желанного огня.

Утром пробежится холодок
И морщинкой ляжет у виска.
И, как потерявшийся щенок,
Заскулит под окнами тоска.

* * *

Мин дауламыйм синнән берни.
Китә алсаң, яп ишекне!
Хаталарсыз, югалтусыз
Бәхеткә соң кем иреште?!

Ут эзләгән сукмакларда
Кычкырсам да җаным көеп,
Мин төннәрдә сине дәшмәм
Һәм үтенмәм кичер диеп.

Иртә таңда йөгерек салкын
Чигәләргә юллар сызар.
Адашкан бер көчек сыман,
Сагыш моңлы җырын сузар.

* * *

Запоминаются последние слова,
И все, что было, ускользает прочь.
Не сможешь ты вернуть мою любовь.

Я в этом не смогу тебе помочь.

Как на снегу, в душе остался след
От слов твоих. Их горечь словно яд.
И я, остановившись на бегу,
Ответ найти пыталась невпопад.

Но сердце разом уловило фальшь
И отдало приказ: «А ну, молчи!»
О сердце, мой прекрасный верный паж,
Не возвращай ему свои ключи.

Я завернусь в холодный синий плащ
И на прощанье лишь махну рукой.
И прикажу себе: «А ну, не плачь!»
Пусть разум мой вернет душе покой.

*** * ***

Истә әле соңгы сүзләр,
Өзгәләнде нечкә кыллар.
Утка яктың сөюемне,
Ябык кире кайтыр юллар.

Ак кардагы эзләр төсле
Уелып калды агу-сүзләр.
Йөгерүдән туктап, күңел
Юанырлык җавап эзләр.

Йөрәк сизде ялган хисне.
«Эндәшмә!» — дип карар бирде.
Түз, йөрәгем, чишә күрмә
Җан төбендә калган серне.

Калтыранып, соң мәртәбә
Томаннарга изим кулны.
Тынычланыр күңелем беркөн,
Акылым табар туры юлны.

*** * ***

Что же ты со мною делаешь,
Человек мой дорогой?
Как испуганная девочка
Я стою перед тобой.

Как подраненная ласточка,
Улететь хочу я вдаль.
Невидимкой-дымкой шапочкой
Спрятать от тебя печаль.

Но глаза твои холодные,
Разбивая, сердце жгут.
Мои мысли сумасбродные
Выход точно не найдут.

Как испуганная девочка
Я стою перед тобой.
Ты сломал такую веточку,
Что назвать бы мог судьбой.

* * *

Ни эшләттең мине, әйтче,
Иң кадерле, якын кешем?!
Күрәсеңме?! Синең алда
Горур башны аска идем.

Хәлдән килсә, карлыгачтай
Очар идем ераккарак.
Яшерергә сагышымны,
Күренмәс бер җепкә урап.

Карашыңда салкын ялкын
Өтеп ала, яна йөрәк.
Шашкын уйлар адашкан да,
Йөри чыгар ишек эзләп.

Горур башны аска иеп
Басып торам алларыңда.
Син сындырдың язмыш дигән
Бер ботакны күз алдымда.

* * *

Убивается любовь
Над несбывшейся надеждой.
Не вернется счастье вновь,
И не будет так, как прежде.

Завязались узелки
Из сомнений и ошибок.
Ручейки из слез горьки
В бороздах былых улыбок.

И букет увядших чувств
В вазу битую не вставишь.
Затуманенную грусть
Ложью слов не одурманишь.

* * *

Хыял кошы кочагында
Өзгәләнә мәхәббәтем.
Янды үткән учагында
Кире кайтмас ак бәхетем.

Төеннәрдән тора язмыш,
Икеләнү, ялгышлардан.
Әче яшьләр ага бары
Сагыш эзләр салган ярдан.

Сулган хисләрнең бәйләмен
Тотып тормый ватык савыт.
Томан сарган кайгыларны
Ялган сүзгә булмый манып.

* * *

Я синицу поймала.

Я ее на ладони держала,
Но до счастья была я жадной:
Мне ее одной было мало.

А вторая летела.
До меня ей не было дела.
Так хотелось ей завладеть!
Да не склеилось. Не успела.

Упустила. Вот жалость.
Руки в праведном гневе сжались,
...А любви моей первой тельце
На дороге лежать осталось...

*** * ***

Бер песнәкне тотып алып
Салдым җылы учларыма.
Бәхет күбрәк кирәк иде —
Мин азсындым аны шуңа.

Икенчесе оча иде,
Аның миндә юк бер эше.
Ә тотасы килә, әмма
Өлгермәдем — тәкъдир көче.

Ычкындырдым. Ни кызганыч,
Ачу белән кыстым учны.
Һушсыз булып ятып калды
Юлда җансыз сөю кошы.

*** * ***

Где-то там далеко,далеко,
Где-то там за дождями, снегами
Было сердцу тепло и легко,
Мы любви нашей песни слагали.

Но ушла в никуда чистота.
В закоулках ушедшего лета
Заблудилась любовь ...А душа,
Словно нищий, в лохмотья одета.

*** * ***

Кайдадыр, еракта, еракта,
Кар-яңгыр болыты артында
Йөрәкләр бер булып типкәндә,
Җыр суздык мәхәббәт хакында.

Үткән җәй тыкрыгы тарайды.
Саф хисләр упкында югалды.
Мәхәббәт адашты. Ә күңел —
Хәерче — киеме ямаулы.

*** * ***

Вычерчу узор вычурный,
Из судьбы тебя вычеркну.

Сердце — воробьишко доверчивый,
Бейся и стучи — только не молчи,
Из дверей своих вынь ключи.
Чур меня! Избавь! Вылечи!
Отстучу прощание азбукой.
Что поделать! Мы с тобой разные.

* * *

Сызармын бормалы бизәкләр
Язмышым китабы битенә.
И йөрәк — беркатлы кошчыгым,
Талпын син, тын калма, үтенәм!
Күңелең ачкычын тартып ал.
Хушлашам өнсезлек телендә.
Йолып ал, терелтче сагыштан!
Без — ятлар мәхәббәт илендә.

## Мы с бедою рядом идем...

Я отрезанный жизнью ломоть,
И меня не намажешь маслом.
Я прогоркла своим несчастьем,
И меня не положишь в рот.

Мы с бедою рядом идем
И уже привыкли друг к другу.
Я ее люблю, как подругу,
Без нее как-то пуст мой дом.

Я хоть знаю, что завтра ждать.
Не питаю иллюзий сладких.
Рядом. Стало быть, все в порядке.
И не надо про счастье лгать.

Пусть мне трудно. А ей легко?
Кто сказал, будто я подарок.
Вон, наделала в жизни помарок
И послала их далеко...

## Бәла белән бергә

Кискән ипи телемедәй
Кибеп беттем әче җилдән.
Ашарга да яраксыз ул,
Теш үтмәсен үзем беләм.

Хәсрәтләрем яннан атлый,
Берекканбез инде бергә.
Якын дустай күреп күптән,
Утырган ул кереп түргә.

Бәхет диеп алданмыйм да.
Чуммыйм татлы хыялларга.
Бәла белән бергә атлыйм
Язмыш дигән зур юлларга.

Авыр миңа. Ә кайгыга
Җиңел мәллә минем белән?!
Озын тормыш юлы буйлап

Хаталарга басып киләм.

* * *

Это что тут жалобно корчится?
А, да это ж мое одиночество.
Что же ты, бедное, маешься?
И бороться со мной пытаешься?
Так. Приоделось и в люди!
Может быть, легче будет...

* * *

Кызгандырып шыңшый ялгызлыгым,
Газаплана язмыш куенында.
Көрәшергә теләп минем белән
Көчен сыный тормыш уенында.
Барыйк әле әйдә кешеләргә,
Җиңел булыр бергә яшәргә.

* * *

Я судьбу благодарю.
Не ругаю, не корю.
У других бывает хуже.
Что, неправду говорю?

У кого-то муж дурак,
У кого-то личный враг,
У кого букет болезней,
У кого на сердце мрак.

Я друзей домой впущу,
Хлебом-солью угощу,
И как нитку сквозь иголку
Все печали протащу.

Будет светлой жизнь моя,
Как в ажуре кисея,
Дом мой будет — полной чашей.
Будем вместе: ты и я.

* * *

Рәхмәтлемен язмышыма.
Ачу да юк, юк шелтә дә.
Башкаларга күпкә авыр,
Ялган диеп кул селтәмә.

Берәүләрнең ире юләр,
Кемнеңдер бар җан дошманы.
Кемнәрнедер сырхау сарган,
Кара йөрәк — хөсет җанлы.

Җан дусларга өйнең түре —
Ипи һәм тоз белән сыйлыйм.
Инәдән җеп үткәргәндәй
Сагышларда җанны сыныйм.

Якты булыр минем тормыш.
Чиккән матур билбау төсле.

Өем — бәхет тулы савыт,
Син һәм мин — без бергә көчле.

## Я выхожу из окруженья

Я выхожу из окруженья
Неумолимых серых дней.
И я с судьбой веду сраженье,
Как с царством мрака и теней.

В моих обрывках подсознанья
Хранятся в пепле бытия:
Мечта, восторженность, признанья,
Любовь и молодость моя.

## Чолганыштан чыгып киләм

Болытлы көннәрдән чыгам,
Өзеп чолганыш чиген.
Бил алышып язмыш белән,
Үземне җиңдем бүген.

Саклый яшәеш җылысын
Минем хәтер төпкелем:
Хыял, соклану, танылу,
Сөю, гүзәл яшьлегем.

# Содержание

От авторов
Авторлардан
Два родника родной земли. *В.Хамидуллина*
Туган якның ике чишмәсе. *Ә.Ситдыйкова*
Где живет счастье. *Н.Алешков*
Иҗатында язмыш бар. *Г.Гыйльманов*

Поэзия Альфии Ситдиковой
*в переводе Веры Хамидуллиной*

**Бер җылы сүз**
**Одно теплое слово**
«Учымда төн...»
«Качаю ночь...»
Җиде төн
Семь ночей
«Хистән исердем, дисең син...»
«Ты говоришь, что пьян от чувств...»
«Иңнәреңә баскан Сөю йөген...»
«Я пришла разделить с тобой ношу любви...»
«Кайт кире...»
«Вернись обратно», — ты зовешь меня...»
«Яратмавың белән яраттырдың...»
«Я не могу назвать тебя любовью...»
«Кирәк түгел гамәл...»
«Как неуместно в чувствах щедрой быть...»
Назга сусау
Жажда ласки
Сөю кошы
Птица любви
«Син йөрәккә шигырь белән...»
«Ты стихами вошел в мое сердце...»
«Син — бүгенге көнем...»
«Ты мой светлый сегодняшний день...»
«Кайнар иреннәрең...»
«Горячие губы ласкают, как пламя...»
Уяну
Пробуждение
Мизгел
Мгновения
Көч
Сила
Тылсымлы көй
Волшебная мелодия
«Үлчәп булмый...»
«Нельзя измерить вспышкой света...»
Ике бөртек энҗе
Две крупицы жемчуга
Яратасым килә
Хочу любить
Наз
Ласка
«Назлардан югалттым башымны...»
«Потеряла голову от ласки...»
Сәгать
Часы
Бер җылы сүз
Одно теплое слово
Болытлар
Облака
Сиреньнәр
Сирень
Кичер мине
Прости меня
«Әллә нишләп үзгәрде...»
«Почему-то изменился мой мир ...»
Бала елый... *(Поэма)*
Плач ребенка *(Поэма)*
«Дөреслекнең йөзе нинди...»
«Какое лицо у правды?..»
Моңлы язмыш
Светлая грусть

Сандугач
Соловей
«Ком бураны, кар бураны...»
«Песчаная, снежная буря, житейская буря...»
«Дөньяны аңларга...»
«Разгадывать мир и друзей обретать...»
«Чиксез галәм киңлегендә...»
«В пространстве галактических широт...»
Яшь
Слеза
«Хыял дәште...»
«Мечта, вздыхая, увлекала вдаль...»
Буталган язмышлар *(Поэма)*
Запутанные судьбы *(Поэма)*
Хәтер җебе
Нить памяти
«Кабат тусаң әгәр, язмышыңны...»
«Представь: тебе пришлось родиться вновь...»
«Чык та төшеп өлгермәгән...»
«Не успела окропить роса...»
«Тормыш китабымның һәр битенә...»
«Не пропуская ни одной страницы...»

Поэзия Веры Хамидуллиной
*в переводе Альфии Ситдиковой*
**Любовь — красивая мелодия**
**Мәхәббәт — ул гүзәл моң**
Я открываю свой альбом
Альбомымны ачам
Мое детство босоногое
Ялан тәпиле балачак
Разноцветные огни
Төрле төстәге утлар
Кораблики
Кораблар
Школьный бал
Чыгарылыш кичәсе
«Я в горстях несу стихи...»
«Ике учым тулы шигырь...»
«Стих новорожденный на суд я принесла...»
«Мин хөкемгә куйдым...»
Эпиграмма
Эпиграмма
«Мы природу видим и так...»
«Табигатьнең һәр фасылы...»
«Льются капли...»
«Таллар елый...»
Рассвет
Таң атканда
«Обрывки памяти нанизывает осень...»
«Сәйләп итеп...»
«Ярко-алая турецкая гвоздика...»
«Ут төсле канәфер чәчәге...»
Законы осени
Көз кануны
«У калины кисти красные...»
«Баланнарның кызыл тәлгәшләре...»
«Любовь — красивая мелодия...»
«Сөю матур көйгә тиңдәш...»
«Мы на разных берегах...»
«Без икебез ике ярда...»
«У меня к тебе претензий нет...»
«Мин дауламыйм синнән...»
«Запоминаются последние слова...»
«Истә әле соңгы сүзләр...»
«Что же ты со мною делаешь...»
«Ни эшләттең мине...»
«Убивается любовь...»
«Хыял кошы кочагында...»
«Я синицу поймала...»
«Бер песнәкне тотып алып...»
«Где-то там далеко, далеко...»
Кайдадыр, еракта, еракта...»

«Вычерчу узор вычурный...»
«Сызармын бормалы бизәкләр...»
Мы с бедою рядом идем...
Бәла белән бергә
«Это что тут жалобно корчится...»
«Кызгандырып шыңшый...»
«Я судьбу благодарю...»
«Рәхмәтлемен язмышыма...»
Я выхожу из окруженья
Чолганыштан чыгып киләм

Заказное издание

*Альфия Ситдикова*
*(**Хазиахметова** Альфия Мирзануровна)*
***Хамидуллина** Вера Петровна*

# Два родника родной земли
# Туган якның ике чишмәсе

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском и русском языках

Редакторы *Р.Х.Курбанов, А.Д.Алишева*
Художник и художественный редактор *Р.Х.Хасаншин*
Техническое редактирование и компьютерная верстка
*С.Н.Нуриевой*
Корректоры *А.Г.Хамитова, Л.З.Шигапова*

С оригинал-макета подписано в печать 12.10.2007. Формат 70Х90 $^{1}/_{32}$.
Бумага офсетная. Гарнитура «Kudriashov». Печать офсетная.
Усл. печ. л. 7,61. Усл. кр.-отт. 7,90. Уч.-изд. л. 5,47.
Тираж 1000. Заказ С-1227.

ГУП Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет подготовлен с помощью пакета программ Jahat™

ОАО ПИК «Идел-Пресс».
420066. Казань, ул. Декабристов, 2.